

ТАРИХИ ЮЛ

М12 трассасын сынап кайтканнан соң уйланулар

> 4

ЗӘЛФИЯ АВЗАЛОВА:

«Бераз эзләсәң, тагын бер Әлфия бардыр ул»

> 5

КЫШКЫ МАВЫГУ

Бозда балык тотуның рәхәте нидә?

> 6

БЕРДӘМЛЕК

«ВТ»ның Татарстанда яшәүче милләтләр турында махсус проекты

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 4–5 (29164–29165) | Сишәмбе | 16 гыйнвар | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

Татарстанда сукбай этләр һәм песиләр өчен 19 приют эшли. Аларда 3 меңләп эт тәрбияләнә. Приютларның икесе муниципаль булса, калганнары шәхси. Узган ел ахырында Аксубай районында сукбай этләр һәм песиләр өчен заманча приют сафка басачагы билгеле булды.

kzn.ru

КЕЧЕ ДУС КАЙГЫСЫ

Әлеге катлаулы һәм җаваплы эшкә алынган Марина Симагина – гап-гади ханым. 2012 елда ул «Вега» дип аталган шәхси приютын ача. Бүген биредә 200 эт һәм 50 песи тәрбияләнә. Аларның күпчелеге – хуҗалары китереп ташлаган хайваннар.

– Без бик каты авырган, машина бәрдергән хайваннарны гына үзебез барып алабыз. Калганнарын барысын да диярлек кешеләр калдырып, ташлап китә. Һәм бу хәл бертуктаусыз күзәтелә. Песиләрне этләргә караганда күбрәк тә кирәксезгә чыгаралар әле. Кышкы суыкларда аларның күпчелеге һәлак та була, – ди ул.

Тик бүген «Вега» приютының хәле авыр. Хайваннарга ризык юк, бурычлары да шактый җыелган.

– Без көч-хәл белән эшлибез. Бурычларыбыз да күп. Приют тоту – чыгымлы эш. Мәсәлән, 200 эткә көненә 75 кг азык кирәк. Бу – 12 мең сум дигән сүз. Ләкин ничек кенә авыр булса да, без бер генә хайванны да урамга чыгарып җибәрмибез. Кайсын хуҗалы итәбез, калганнары соңгы көннәренә кадәр бездә яши. Мин бу эш белән 10 еллап шөгыльләнәм инде. Балачактан бирле хайваннарны яраттым, аларны кызгандым. Миңа аларны карау, тәрбияләү рәхәт. Тормышымны алардан башка күз алдына да китермим. Бу – минем үзем теләгән һәм гомер буе хыялланган хезмәтем, – ди Марина Симагина.

Зур, заманча приют төзү дә – аның күптәнге хыялы. Һәм, ниһаять, узган ел тәвәккәлләп, шушы эшкә алынган.

– Авыл халкына этләр өрүе дә комачаулагач, район башлыгы Камил Гыйльманов безгә торак пунктлардан читтәрәк җир бүлеп бирде. Һәм без, грант отып, приют төзү эшен башлап җибәрдек. Анда ничә песи һәм эт урнаштырылачагын алдан әйтә алмыйм. Тәҗрибә күрсәткәнчә, моны алдан планлаштырып та булмый, чөнки алар көн саен артып тора, – ди ул.

Тик, Марина әйтүенчә, эшләр башланган да тукталып калган. Төп сәбәбе – финанс мөмкинлекләре булмау.

– Яңа, заманча приютның кайчан төзелеп бетәчәген мин берничек тә әйтә алмыйм, чөнки бу – бик зур суммалар сорый торган объект. Яхшы приют төзер өчен 10, 20 млн сум да җитми. Әле без «Татнефть»нең грант акчасын да күптән түгел генә оттык, ләкин әлегә ул акча безгә килеп ирешмәде. Ә болай ара-тирә эшмәкәрләр, яхшы күңелле кешеләр булыша. Шулай да бу эшне ахырга җиткерү – минем хыялым, – ди Марина Симагина.

Аксубай районы башлыгы Камил Гыйльманов сүзләренчә, сукбай этләр проблемасы – иң актуаль мәсьәләләрнең берсе.

> Соңгы елларда алар бик артты. Кырларда, урманнарда да, мәктәп, балалар бакчалары тирәләрендә дә күренәләр, халыкның терлекләренә дә зыян салалар. Шуңа күрә без Маринага ярдәм кулы сузарга булдык. 5 млн сум күләмендә «Татнефть» грантын оттык, 10 млн сумын хайваннар яратучы ханым үзе финанслый. Иганәчеләрнең дә ярдәме кирәк булачак. Без исә җир, транспорт, гомумән, нинди ярдәм кирәк, шуның белән булышабыз. Барысы да планлаштырылганча барса, приютны бер ел эчендә төзеп бетерергә ниятлибез, – диде Камил Гыйльманов.

Районның баш ветеринары Рәис Хөснуллин әйтүенчә, узган ел Димитровград шәһәрендәге оешма хезмәткәрләре районда 86 этне аулаган. Моның өчен аларга 300 мең сум акча бирелгән.

– Безгә сукбай этләр буенча мөрәҗәгать итүчеләр юк. Гадәттә Авыл советларына һәм шәһәр башкарма комитетына киләләр. Безгә авырган этләрне генә алып киләләр. Миңа калса, сукбай этләр һәм песиләр буенча мәгълүматны беркем дә әйтә алмый торгандыр. Алар арта тора, кайсыларыдыр суыкта һәлак була, аулана яки приютка тапшырыла, – диде ул.

Сукбай этләр проблемасын ничек хәл итеп була соң? Әлеге сорауга «Вега» приюты хуҗасы Марина Симагина болай дип җавап бирде:

– Кешеләрдә җаваплылык хисе кайчан барлыкка килә, сукбай этләр шул вакытта гына кимеячәк. Бездә халык хайваннарга карата җавапсыз. Йорт хайванын алганда алалар, тик үз көчләрен исәпләп бетермиләр. Уйнап туйгач, урамга чыгарып җибәрәләр яки, капчыкка салып, безгә китереп ташлыйлар. Шуңа күрә йорт хайваннарын учетка алуны, чиплаштыруны мәҗбүри итү кирәк. Чыгарып ташлыйлар икән, зур күләмдә штраф түләтү дә мәҗбүри булырга тиеш, – ди ул.

Учетка алырга кирәк дигән фикерне кинолог Павел Леонов та әйтте.

– Бу очракта кешеләр үзләре гаепле, – ди белгеч. – Моннан тыш, сукбай этләр артуның төп сәбәпләренең тагын берсе – азык табу белән авырлык булмау. Ачык чүп савытлары, пакет белән ташланган ризыклар бөтен җирдә бар.

Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәгълүматлары буенча, быел этләрне аулау өчен бюджеттан 88,3 млн сум акча бүлеп биреләчәк. Аның 29 миллионы агрессив этләрне карап тоту өчен китәчәк. Республикада ел саен якынча 20 меңләп эт аулана. Ә приютны СанПиНның барлык кагыйдәләре буенча төзү өчен якынча 100 млн сум акча кирәк. Аларны карап тоту да арзан түгел: әгәр 4–5 ел элек бер этне асрау 107 сум булса, хәзер бу 150 сумга җитә.

Сукбай этләр белән эшләүчеләр аларны теркәүгә зур игътибар бирергә кирәклегенә басым ясасалар да, хайваннарның хуҗалары ашыкмый. Әйтик, хәзерге вакытта республикада 110 мең эткә вакцина ясалган, ә нибары 14 меңе генә теркәлгән.

Хәрбиләргә хат

Татарстанда яшәүчеләр узган елда махсус хәрби операция зонасына 5 меңнән артыграк хат һәм посылка юллаган. «Татарстан почтасы» матбугат хезмәте хәбәренә караганда, 1 майдан почта бүлекләре хәрбиләргә җибәреләсе әйберләрне бушлай кабул итә.

Посылкада яки хатта хәрби частьның номеры, солдатның Ф.И.О. һәм адресы («Мәскәү ш., 103400») күрсәтелергә тиеш. Посылка Мәскәүдә Оборона министрлыгы вәкилләренә тапшырыла. Алар, үз чиратында, күчтәнәч яки хатларны ияләренә китереп бирә.

Почтада күчтәнәчләр ачык килеш кабул ителә (тыелган әйберләр, әйтик, тиз бозыла торган ризыклар кире кайтарыла). Һәрбер посылканың авырлыгы 10 килодан артмаска тиеш. Кирәк булганда, күчтәнәч берничә тартмага салып җибәрелә.

2023 елда хәрбиләргә шундый ысул белән барлыгы 160 мең посылка һәм хат юлланган.

Үзе китә, бүләге кала

Яңа ел каникулы чорында Татарстанга килүче туристлар банк карталары белән 916 миллион сумнан артыграк акча түләгән. Казанның Туризмны үстерү комитеты җитәкчесе Дарья Санникова әйтүенчә, 31 декабрьдән 8 гыйнварга кадәр Казанда барлыгы 167 мең турист булып киткән. Чагыштыру өчен: Түбән Новгородка – 190 мең, Санкт-Петербургка 1 миллион чамасы кеше сәфәр кылган.

«СберАналитика» мәгълүматларына караганда, туристларның 55 проценты – ил төбәкләреннән, 41 проценты республика районнары һәм шәһәрләреннән килгән. Бәйрәм көннәрендә Татарстанга Россиянең 83 төбәгеннән кунаклар килеп киткән. Туристлар арасында Мәскәүдән, Санкт-Петербург, Ульяновск шәһәрләреннән һәм Мари Эл Республикасыннан килүчеләр бигрәк тә күп булган.

Санникова билгеләп үткәнчә, кунакларның 56 процентын – хатын-кызлар, 44 процентын ирләр тәшкил иткән.

Җанисәп башланган

Кичә республикада җәнлекләрнең кышкы исәбен алу башланган. Биоресурслар буенча дәүләт комитеты мәгълүматларына караганда, 19 төрдәге ау хайванын санау буенча дәүләт күзәтүендә һәр ел саен үткәрелә торган чара бу.

Татарстан территориясендә яшәүче хайваннарның исәбен алуда комитет, ау хуҗалыгы белгечләре, урман карауччылар, җәмәгать инспекторлары һәм аучылар катнаша. Аларга 14 мең чакрымнан артыграк юл узарга туры киләчәк.

Быел ул өч ысул белән оештырылган: җәнлекләрнең баш санын кышкы юллары буйлап барып, куркытып (аннан – эзләре буенча) һәм ашату урыннарына барып санаячаклар. Ау биләмәләрендә җәнлекләрнең саны турында дөрес мәгълүмат алу мөмкинлеге бирәчәк бу.

Исәпкә алу эшләре 15 мартта төгәлләнәчәк. Шул рәвешле тупланган мәгълүматлар җәнлекләрнең санын бәяләү, кирәк булган очракта – аларны саклау, баш исәбен арттыру чараларын күрү мөмкинлеге бирәчәк.

Җылыта

Татарстанда 0 градуска кадәр җылыта. Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, чәршәмбе – 17 гыйнварда көндез термометрның терекөмеш баганасы 0…–5 градус күрсәтәчәк. Төнлә 0…–7 градус. Юеш кар, буран, секундына 24 метр тизлектә көчле җил.

Пәнҗешәмбе – 18 гыйнварда көндез һава температурасы –8…–13 градус чикләрендә тирбәләчәк. Явым-төшем көтелми. Җомга һәм шимбә – 19, 20 гыйнварда көндез –1…–6, төнге сәгатьләрдә –12…–17 градус булачак. Юеш кар, буран, көчле җил, юлларда – бозлавык.

КФУ белгече Тимур Әүхәдиев әйтүенчә, гыйнвар башы бик суык килсә, якындагы ун көндә, киресенчә, аномаль җылы булачак. Һава температурасының нормадан (–9,7 градус) 2–3 градуска югарырак күтәрелүе фаразлана. Ә якындагы көннәрдә температура нормадан 6 градуска ук артып китәчәк. Метеоролог сүзләренә караганда, кыш азагына кадәр аномаль суыкның яңа дулкыннары булырга мөмкин әле. Карга килгәндә, бүгенгә азрак яуган кебек тоелса да, кар катламы биеклеге нормадан артып киткән. «Норма буенча – 32 мм, ә бездә 41 мм инде», – дигән метеоролог.

Көн кадагында

Битлек кенә коткармый

Кызамык тарала! Күпләр вируслы чирләр белән көрәшеп яткан шушы көннәрдә белгечләр тагын бер шомлы хәбәр ирештерде. Кызамык йоктыру очраклары турында хәбәрләрне узган ел да ишетеп тордык аныcы. Әмма быел вазгыять күпкә мөшкелрәк булырга охшап тора. Яңа елның беренче ике атнасында республикада инде 20 (!) кешенең кызамык белән чирләве ачыкланган.

Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе башлыгы Марина Патяшина сүзләренә караганда, әлеге мәкерле чир белән авыручылар саны елдан-ел арта бара. Чагыштыру өчен: узган ел республикада кызамык йоктыруның 146 очрагы теркәлгән булган. 2022 елда исә бу чир бер кешене генә аяктан еккан.

– Әле ел башланырга да өлгермәде, Татарстанда 20 кеше кызамык йоктырырга өлгергән инде. Шуларның өчесе – республикага читтән эшкә килүчеләр. 13 кеше бу чирне башка төбәктә чакта йоктырган, – ди идарә башлыгы.

Республикада соңгы тапкыр кызамык йоктыру очрагы «Салават Күпере» микрорайонында теркәлгән. Биредә яшәүче ике кешегә шундый диагноз куелган. Икесе дә – Таҗикстаннан Татарстанга эшкә килүче. Белгечләр әлеге чирдән саклану өчен бердәнбер нәтиҗәле ысул дип кызамыкка каршы вакцина ясатуны атый. Әле декабрь азагында гына республикага 9910 доза вакцина кайткан. Ул республиканың барлык дәвалау оешмаларына таратылган.

Белгечләр кызамыкны яшен тизлегендә таралучы мәкерле чир дип атый. Әйтик, күпфатирлы йортта берәрсе шул чирне йоктырган булса, бу чир вентиляция торбалары аша тиз арада йортта яшәүче бар кешене аяктан егарга мөмкин. Шуңа күрә авыру кеше белән бер йортта яшәүчеләргә кичекмәстән кызамыкка каршы вакцина ясатырга куша белгечләр.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов сүзләренә караганда, хәтта коронавирус та шулкадәр тиз йокмый.

– Кызамык йоктырган кеше белән аралашкан булсаң, 100 процент очракта үзең дә чирләячәксең. Әлеге чирдән ниндидер махсус дарулар, битлек ярдәмендә дә саклана алмыйсың. Фәкать вакцина ярдәмендә генә сакланып була, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә. – Илкүләм прививкалар календаре буенча, 55 яшькә кадәр кешегә кызамыкка каршы ике прививка ясалган булырга тиеш. Ул аңа гомере буена җитә. Бу прививкалар документ нигезендә теркәлгән булырга тиеш. Юкса еш кына: «Миңа балачакта кызамыкка каршы прививка ясалган булган инде, әни шулай дип әйтте», – ише сүзләрне еш ишетергә туры килә. Бу – ялгыш фикер. Әгәр кеше үзенә кызамыкка каршы прививка ясалганмы-юкмы икәнлекне төгәл белмәсә, ул моңа тәгаен инанып өчен эхинококка IgG антитәнчекләр анализы тапшырырга тиеш. Әгәр кешенең бу чиргә каршы иммунитеты юк икәнлеге ачыкланса, аңа кызамыкка каршы ике прививка ясатасы булачак. Ике прививка арасында өч ай вакыт үтәргә тиеш.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Анатолий ДОМНИКОВ, Россия Сәламәтлек саклау тармагы хезмәткәрләренең профсоюз рәисе, Иҗтимагый совет башлыгы:

Табибларның кәгазь эшен киметергә кирәк. Кәгазь амбулатор картадан тулысынча бердәм электрон медицина документына күчкәч, табиб, базага кереп, кешенең бөтен авыру тарихын күрә алачак. Авырулар, бигрәк тә өлкән яшьтәгеләр кайчан, нәрсә белән авырганын хәтерләп бетермәскә дә мөмкин бит.

(«Парламентская газета» басмасыннан)

БӘЙРӘМНӘРДӘ ТОТЫЛГАН АКЧА

Россия халкының озын ялларда (1–8 гыйнвар) акчасы нәрсәгә сарыф ителгән?

	Уртача чек (сум)
Электроника һәм көнкүреш техникасы	10138
Кунакханә	7995
Спорт товарлары	2572
Матурлык салоны, чәчтарашханә	1624
Балалар, гаилә өчен күңел ачу үзәкләре	1602
Автоягулык	1149
Азык-төлек кибете	788
Даруханә	753

*Платформа ОФД мәгълүматлары буенча



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

«ИКС» ЧИРЕ ЕГЫП САЛМАСМЫ?

Үткән атнада табигый һәм социаль катастрофалар спирале моңарчы күрелмәгән тизлектә бөтерелде. Вакыйгалар шулкадәр кыза һәм тизләнә: кайсының мөһимрәк икәнен аерып әйтү дә кыен.

Башында Вашингтон торган коалиция Йәмәнне бомбага тота. Якын Көнчыгыш кризисының җәелүе кысасында мондый һөҗүм көтелә иде. Йәмән каршылыгы утка тотуның үзенә зур зыян салмавын белдерә һәм Кызыл диңгез аша йөрүче Израиль корабларын утка тотудан туктамаячагын әйтә. Хәзер инде АКШ һәм Европа корабларына да куркыныч яный, нефть ташучы танкерлар бикләнә. Нәтиҗәдә кара алтын бәясе күтәрелде. Йәмән соңгы ике дистә ел эчендә туктаусыз утка тотулар астында яши, ә янкиларның яңа һөҗүмнәре вазгыятьне көнбатышлылар файдасына үзгәртер дигән өмет аз.

Тайваньда шимбә көнне сайлау булып узды. Утрау җитәкчелегенә кем килүенә бәйле рәвештә ул Кытай белән мөнәсәбәтләрне хәл итәргә тиешле иде. Сайлауда Кытайдан бәйсезлек тарафдары Лай Циндэ җиңде. Бу материк белән утрау арасында вазгыятьне кискенләштерә. Безнә хәтта сугыш башлану ихтималлыгы белән куркыталар. Андый сугыш була калса, дөнья икътисады җимереләчәк, диләр. Хәл, чынлап та, кискен, әмма коткы таратучылар әйткән дәрәҗәдә үк түгел. Пекинның сугыш башлау ихтималлыгы кечкенә. Без хәтта куркыныч әйтә алабыз: нульгә якын. Кытай утрауга каршы икътисадый санкцияләр кертеп кенә дә андагы вазгыятьне җимерелү дәрәҗәсенә кискенләштерә ала. Икенчедән, кытай армиясе сугышка әзер түгел. Өченчедән, Лай сайлау кампаниясе вакытында ук җиңгән очракта бәйсезлек игълан итәргә җыенмавын белдергә. Дүртенчедән, сайлауда администрация башлыгы буларак Лай җиңсә, парламентта Гоминьдан партиясе өстенлек алды. Ул партия «Бер ил – ике система» дигән формула яклы, ягъни Пекин идарәсе астына керүне хуәтли.

Безнең өчен куркыныч яңный торган факт дип Давоста бу атнада ачылачак Бөтендөнья икътисад форумының көн тәртибенә «Икс» пандемиясенә әзерлек мәсьәләсен кертелүен саныйм. Чир әлегә үзе юк, әмма аның коронавируска караганда 20 тапкыр күбрәк кешене кырасын белдерәләр иде. Коронавирус пандемиясе алдыннан да шулай булган иде. Димәк, яңа ясалма чир таралу куркынычы зур. Америкада болан үлуенә китергән вирус яңа үтерүче роленә әзерләнә. Ул әлегә кешеләргә йокмый.

Конспирологларның, гыйнварның 23еннән башлап 15 февральгә кадәр глобаль финанс җимерелүе әзерләнә, дигән имеш-мимеш хәбәре бар. Андый куркытулар гадәттә тормышка ашмый, әмма түнтәрелеш теләүчеләр җитәрлек.

Россиядә

БЮДЖЕТНЫ ВАЛЮТА САТЫП ТУТЫРУ

Роспотребнадзор яңа пандемиягә үзенең мөнәсәбәтен белдерде: «Икс» чире турындагы сүзләр фәнни түгел, ә икътисадый мотивларга бәйле булырга мөмкин. Чынлап та, дөнья икътисады авыр чор кичерә. Франциядә һәм Италиядә сәнагать җитештерүе 1990 ннчы еллар дәрәҗәсенә түбәнәйгән, Германиядә – 2010 ел күләмендә. Мондый шартларда глобаль финанс мафиясе я сугыш чыгара, я пандемия байрагын күтәрә. Агымдагы вазгыятьтә без боларның икесенең дә ихтималы үсүен күрәбез.

Ел нәтиҗәләренә караганда, Россия икътисадына хәләләр түзәрлек. Статистика хәтта сөенечле саннарны да байтак китерә. Соңгы көннәрдә коммуналь хуҗалык аварияләренең эпидемия төсле бер шәһәрдән икенче шәһәргә таралуын искә алмаганда, икътисадта да, социаль өлкәдә дә хәлләр ярыйсы.

Финанс министрлыгы бюджет үтәлеше турында хисабын бирде. Керемнәрнең нефть-газ тармагына карамаганнары 20,3 триллион сум тәшкил иткән. Бу алдагы ел белән чагыштырганда 25 процентка күбрәк. Сан бик зур, ул эшкәртү сәнәгатенең куәтле адымнары турында сөйли кебек. Сәнәгатьтә күтәрелеш булса да, андый ук зур адымлы түгел түгелгән. Күрәсең, бәяләр күтәрелү һәм долларның үсеше өстәмә финанс агымнары белән тәэмин иткәндер.

Нефть-газ керемнәре 8,8 триллион сум булган. Болары узган елдагы белән чагыштырганда 23,9 процентка кимегән. Шуларның барысын исәпкә алгач, федераль бюджет керемнәре 4,7 процентка үскән, чыгымнар 4 процентка арткан. Бюджет дефициты – 3,3 триллион сум.

Бюджетны гадәттә бурычка алып каплыйлар яисә валюта резервларын саталар. Соңгы көннәрдә без сумның ныгуын күзәтәбез. Бу – Финанс министрлыгының һәм Россия банкының валюта белән алтын сатуы нәтиҗәсе. 15 гыйнвардан башлап федераль хөкүмәт соңгы биш айда беренче тапкыр шундый сәүдәгә керешә. Финанс министрлыгы – көн саен 4,1 миллиард сумлык, ә Россия банкы 12,6 миллиард сумлык валюта сатуны планлаштыра. Белгечләр, сум 85–87 сумга кадәр ныгыр, диләр. Әлеге сәүдә берьюлы ике мәсьәләне хәл итә: бюджет дефицитын каплый, Президент сайлау алдыннан тотрыклылык иллюзиясе бирә. Марттан соң валюта курсы ничек буласын әйтеп булмый, ә агымдагы вазгыятьтә валютаны сату түгел, сатып алу отышлы.

Белгечләр Россия резервлары 2024 елга җитәчәген әйтә. Нефть бәясе кискен үсеп китсә, акча, бәлки, 2025 елга да калыр әле.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ЫШАНЫЧЛЫ БӘЙРӘМ

Прокурорлар республикада законлылык һәм хокук тәртибен саклау юнәлешендә катлаулы һәм җаваплы бурычны намус белән үтиләр. Бу хакта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Россия Прокуратурасы хезмәткәрләре көненә багышланган чарада әйтте. Бәйрәмдә Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да катнашты.

Тантаналы чара Россия Президенты Владимир Путинның видеокотлавы белән башланды. Илбашы прокуратураны дәүләт хакимиятенең иң мөһим институтларыннан берсе дип атады.

Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, гражданнарның, шул исәптән өлешчә мобилизациягә эләккән гаиләләрнең, балигъ булмаганнарның, эшкуарларның социаль-икътисадый хокукларын яклау, икътисад өлкәсендә, оборона-сәнәгать комплексында законлылыкны тәэмин итү, җинаятьләргә каршы тору – республика прокуратурасы карамагындагы өстенлекле мәсьәләләрнең бер өлеше генә. Аларның намуслы эше социаль-икътисадый һәм иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны сакларга ярдәм итә. Татарстан Рәисе бу елның республикада вакыйгаларга бик бай булачагын да искәртте. «Прокурорлар ярдәме белән без аларны югары дәрәҗәдә үткәрергә, иминлекне тәэмин итәргә тиеш», – диде Рөстәм Миңнеханов.

– Татарстан җитәкчелеге республика алдында торган бурычларны хәл итүдә сезнең ярдәмегезне һәрвакыт тоя. Хезмәтегез һәм эшегезгә тугрылыгыгыз өчен чын күңелдән рәхмәт белдерәсем килә. Сезнең һәркайсыгыз үз җаваплылыгын тулысынча аңлый һәм бу елда эшне гадәттәгечә югары дәрәҗәдә дәвам иттерәчәксез, дип ышанам, – диде республика җитәкчесе.

Татарстан прокуроры Альберт Суяргулов билгеләп үткәнчә, былтыр республика Прокуратурасында 106 меңгә якын мөрәҗәгать кабул иткәннәр, шулай ук шәхси кабул итүләр барышында 23 меңнән артык шикаять теркәлгән. «Болар барысы да халыкның прокурорларга ышанычының югары дәрәҗәсе турында сөйли», – диде ул.

tatarstan.ru

– Һәр мөрәҗәгатьтә кеше язмышы тора. Тормышның төрле өлкәләрендә гражданнарның, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең хокукларын яклауга бәйле 35 мең прокуратура акты төзелгән. Бу – прокуратура хезмәткәрләре вәкаләтләренең бик аз өлеше генә, – диде Татарстан прокуроры.

Битлек кенә коткармый

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Кызамыкка каршы прививка, иң беренче чиратта, балаларга ясалырга тиеш, дип саный белгеч. Ник дигәндә, алар бу чирне авыррак уздыра. Авырып терелгәннән соң да җитди өзлегүләр күзәтелергә мөмкин.

– Бу чир белән авыргannan соң, өлкәннәрдә пневмония башланырга мөмкин. Балалар өчен хәлләрнең тагын да аянычрак тәмамлануы бар. Ник дигәндә, кызамык аркасында баланың баш мие тулысынча ялкынсынырга (панэнцефалит) мөмкин. Иң куркынычы шул: әлеге чир бала кызамык белән авырып терелгәннән соң биш еллап вакыт узгач кына пәйда була. Бала начар укый, башы авыртудан зарлана башлый. Авыру торган саен көчәя генә. Ата-ана эшнең нидә икәнен аңлый алмыйча тилмерә. Ахыр чиктә, бала инвалид калырга мөмкин. Ул нәкъ инсульт кичергән кеше кебек хәрәкәтләнә, сөйләшә алмый башлый, башы эшләми. Шуңа күрә балаларга иң беренче чиратта кызамыкка каршы прививка ясалырга тиеш, – ди Дмитрий Лопушов.

Белеп тор!

Кызамык күбрәк 2–5 яшьлек балалар арасында ачыклана. Ул еш кына гадәти ОРВИ кебек башлана. Шуңа күрә баштарак табиб аны төгәл ачыклап бетермәскә дә мөмкин. Беренче көннәрдә бала йөтәлли, тамагы авырта, борыныа томау төшә. Аны бизгәк тотарга, күзенә коньюнктивит чыгарга да мөмкин. Әмма кызамык башлануның дүртенче көнендә тәнгә кызыл тимгелләр чыга башлый. Ул тиз арада тарала, артканнан-арта бара. Баштан алып аяк бармакларына кадәр кызыл тимгелләр баса. Бала коңгырт кызыл төскә керә. Тәнгә тимгел чыкканда баланың температурасы 40 градуска кадәр күтәрелә. Ул яктылыктан курка башлый. Дүрт көн дәвамында баланың температурасы бик югары була. Аннары тимгелләр акрынлап кими.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Каләмегез үткен булсын!

Дәүләт Советында

«Сездән башка депутат тавышын да, Хөкүмәт карарын да беркем ишетмәячәк». Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, республиканың массакүләм мәгълүмат чаралары җитәкчеләрен, журналистларны һөнәри бәйрәмнәре – Россия матбугаты көне уңаеннан котлап, шулай диде.

Россия матбугаты көне Петр I указы нигезендә оештырылган тәүге басма – «Ведомости» газетасының чыга башлау көненә бәйле. Газетаның беренче номеры моннан 321 ел элегрәк пәйда булган.

Дәүләт Советы Рәисенең журналистлар белән очрашуы «Казан» Гаилә үзәгендә узды. Очраклы түгел, чөнки 2024 ел Россиядә Гаилә елы буларак игълан ителде.

– Сез – мәгълүматны беренчеләрдән булып эзләп табып, аны укучыларга, тамашачыларга һәм радио тыңлаучыларга җиткерүчеләр, сезнең аша без Татарстанның күпмилләтле халкы белән элемтә булабыз. Гаять зур җаваплылык һәм гаять зур хезмәт бу. Үз каләмегез белән сез һәрбер кешенең күңеленә барып җитәсез», – дип мөрәҗәгать итте журналистларга парламент Рәисе.

Фәрит Мөхәммәтшин очрашуда журналистлар династияләренең ролен аерым билгеләп үтте, үз һөнәрен буыннан-буынга тапшырып килүче тармак ветераннарына рәхмәт белдерде. Ул шулай ук 175 миллет вәкилен үзенә сыендырган Татарстанда массакүләм мәгълүмат чараларының рус, татар телләрендә, республика халыкларының башка туган телләрендә эшләвенең мөһимлеген искәртте.

Парламент Рәисе бүген турыдан-туры махсус хәрби операция зонасында эшләүче журналистларга аерым рәхмәт сүзләре белдерде. «Дөньядагы хәлләр бик катлаулы. Халкыбызга махсус хәрби операция турында, Россияне саклаучы солдатлар һәм каһарманнарның батырлыклары турында дөресен сөйләвегез өчен рәхмәтлемен», – диде парламент башлыгы.

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев тә коллегаларын һөнәри бәйрәмнәре белән котлады. «Узган ел вакыйгаларга һәм казанышларга бик бай булды. Агымдагы елның да шундый булачагына ышанабыз. Алда – «Киләчәк уеннары», ике сайлау кампаниясе, БРИКС саммиты һәм башка чаралар», – дип искә төшерде ул.

Очрашу ахырында Фәрит Мөхәммәтшин һәм Айдар Сәлимгәрәев «иң-иң»нәргә бүләкләр тапшырды.

ӨЙДӘ БУРАН БУЛМАСЫН

Борчыган мәсьәлә

Дәүләтнең үсеше дә, иминлеге дә гаиләгә бәйле. «Волга» экспертлар клубының беренче утырышында бу фикер еш яңгырады. «Демография» илкүләм проектының нәтиҗәләре һәм яңа бурычлары турында фикер алышырга җыелган белгечләрнең елны шул хакта сөйләшүдән башлавы юкка түгел, билгеле. Бу ел ил күләмендә Гаилә елы дип игълан ителде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстан хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова сүзләренә караганда, республикада «Демография» илкүләм проекты уңышлы гына гамәлгә ашырылып килә. Бүген Татарстанда яшәүче 50,2 мең күпбалалы гаилә дәүләт ярдәменнән файдалана.

– Демографик вазгыять дигәндә, без иң беренче чиратта күпбалалы гаиләләрнең санын күздә тотабыз. Моннан ун ел элек республикада шундый 24 меңнән артык гаилә исәпләнә иде. Бүген аларның саны 50 меңнән артты, – ди министр.

Эльмира Зарипова бу уңайда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов карары белән республикада яшәүче күпбалалы гаиләләргә балалар бакчасы өчен түләүдән ачканын 100 процент күләмендә кире кайтуын да искәртте. Моннан тыш кечкенә балалары булган гаиләләргә дару алу өчен елга бер тапкыр 10 мең сум күләмендә акчалата компенсация бирелә. Хәзерге вакытта республикада барлыгы 61 төрле социаль ярдәм чарасы тормышка ашырыла. Эльмира Зарипова сүзләренә караганда, узган ел министрлыкта тотылган һәр ике сумның берсе гаиләләргә ярдәм күрсәтү өчен булган.

Россия хезмәт министры урынбасары Андрей Пудов бүген илдә гаиләләргә ярдәм чараларының тулы бер системасы формалашуын искәртте. Бу ярдәмнән шәһәрдә яшәүчеләр дә, авыл халкы да бер үк дәрәҗәдә файдалана ала.

– Узган елның 1 гыйнварыннан гаиләләргә ярдәмнең тулы бер системасы гамәлгә ашырыла башлады. Бүген балага карында чакта ук пособие түләнә башлый. Хәзер әниләр 380 мең сумга кадәр пособие ала. Пособие балага 17 яшь тулганчы түләнә. Хәтерләсәгез, унбиш ел элек аена нибары 50 сум пособие түләнә иде бит, – ди Пудов.

Тик дәүләт тарафыннан нинди генә шартлар тудырылса да, демографик упкын әле дә булса саклана бирә. Россия Дәүләт Думасының хезмәт, социаль сәясәт һәм ветераннар эшләре буенча комитет рәисе Ярослав Нилов яшерми: олыгаеп бала алып кайтучылар, нәселсезлектән интегүче парлар саны арту, карьера ясыйм дип гомумән бала табудан баш тартучылар саны күбәю аеруча куркуга сала.

– Монда аларны тәнкыйтьләү, мәҗбүриләүдән мәгънә юк. Яшьләр белән аларга аңлаешлы телдә сөйләшергә кирәк. Без аларга үзләре уңай карар кабул итәрлек алшартлар тудырырга тиеш. Гаилә кыйммәтләрен ничек тә сакларга кирәк. Бу кыйммәтләрне дошман да үз максатында файдаланырга мөмкин. Дәүләткә каршы гаиләләрне җимерү юлы белән көрәшәчәкләр, – дип тә кисәтте ул.

Нилов фикеренчә, мисал эзләп ерак китәсе юк. СССР таркалган чорда илдә хөкем сөргән вазгыятьне, ил өчен ят булган рухи кыйммәтләр урнашкан чорны искә алу да җитә. Нилов «Демография» проектының иң төп бурычларының берсе дип әнә шул хәлләрне кабат булдырмауны атый.

– Россия хөкүмәтендә бу проектның яңа юнәлешләре турында фикерләр яңгырый башлады. Алар күбрәк халыкның мәшгульлегенә юнәлтелер дип көтелә. Пандемия чорында илдәге эшсезләр саны 4 миллион тәшкил иткән булса, бүген ил күләмендә андыйлар 400 мең чамасы. Илебез демографик проблемаларын хәл иткән очракта гына көчле булачак, – ди Нилов.

«Диалог Регионы» коммерцияле булмаган автоном оешмасы күптән түгел республика халкы арасында махсус тикшеренү уздырган. Татарстанлыларның дәүләт тарафыннан каралган ярдәм чаралары, республикадагы үзгәрешләр турында ни дәрәҗәдә хәбәрдар булуын ачыкларга алар. Сораштыруда 414 кеше катнашкан. Аларның күбесе ана капиталы, гаилә ипотекасы, балалар пособиеләренә бәйле үзгәрешләрне күзәтеп баруын белдергән. Респондентларның 90 проценты 2024 елның Гаилә елы дип игълан ителүеннән хәбәрдар булуын әйткән.

Россия Дәүләт Думасы депутаты Ольга Павлова, демографияне яхшырту өчен гаиләләргә матди ярдәм күрсәтү генә җитми, рухи кыйммәтләр турында да онытмаска кирәк дип саный. «Бүгенге шартларда баланнан да бигрәк гаилә кыйммәтләрен торгызырга кирәк. Шуңа күрә ил башлыгының Гаилә елын игълан итүе аеруча сөендерә», – диде депутат.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

БЕЛЕМ МӘРӘКӘСЕ

ЯҢАРТЫЛГАН МӘГАРИФ ЭЛЕКТРОН СИСТЕМАСЫНДА НИНДИ ҮЗГӘРЕШЛӘР КӨТЕЛӘ?

Илдар Мөхәммәтҗанов

9 гыйнвардан республикада яңартылган мәгариф электрон системасы эшли башлады. Шул сәбәпле әти-әниләр арасында теркәлүгә бәйле төрле ризасызлыклар да шактый туды. Аны хәл итү юлларын белгечләр катнашында узган республика онлайн ата-аналар җыелышында бергәләп эзләделәр. Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин әти-әниләрне, техник көйсезлекләр вакытлыча гына, дип тынычландырды.

– Рәис Рөстәм Миңнеханов республика мәгариф системасын яңартуга бәйле сораулардан читтә калмады. Һәр яңа әйбер аңлатуны таләп итә. Без әти-әниләр белән очраштык. Күпләре: «Барысы да канәгатьләндерә», – дисә дә, ачыклыйсы сораулар да бар әле, – дип башлады онлайн җыелышны республика вице-премьеры Ләйлә Фазлыева.

«Керә алмыйбыз, мәшәкате күп», «Нигә элеккегесе генә ярамый?», «Электрон көндәлеккә кереп, билгене карап булмый», «Нигә без балага кагылышлы шәхси мәгълүматны бирергә тиеш?» Сораулар күп, җавап биреп кенә өлгер. Ахыр чиктә, теркәлү мәшәкатеннән туеп, кирәкми, дип кул селтәүчеләр дә бар икән. Кыскасы, әти-әниләр әлеге системаны өр-яңа дип кабул итә. Республиканың санлы трансформацияләү үзәгендәге мәдәният, мәгариф һәм яшьләр сәясәте өлкәсендә цифрлы трансформация бүлеге җитәкчесе Булат Габдрахманов: «Яңа түгел, яңартылган», – дип басым ясап, нечкәлекләрен аңлатып үтте. Ул белдергәнчә, «Татарстанның электрон белем бирү системасы» платформасы (edu.tatar) 2009 елда файдалануга тапшырылган һәм ул яңартуны таләп иткән. Сораштыруда катнашкан укытучыларның яртысы платформаны яңартырга кирәклеген әйткән. Хәзер республиканың барлык мәктәпләре дә «Минем мәктәп» федераль сервисы нигезендә яңартылган системада (ms-edu.tatar.ru) эшли. Нәтиҗәдә иске портал 75 процентка үзгәргән. Димәк, мөмкинлекләр дә арта дигән сүз. Яңасына электрон журнал, «Мәскәү электрон мәктәбе» (МЭШ) көндәлекләре кертелгән. Имтиханнарга әзерләнү өчен материаллар урнаштырылган. Әти-әниләр өчен китапханә дә бар. Укытучылар өчен кушымталар булдырылган. Белгечләр, педагогларның хисап эше кимеячәк, дип ышандыра. Хәер, укытучылар әле соңгысына ышанып та бетми. Әмма арада: «Өстәмә материаллар күп. Темаларны сентябрьдә тутырып куйсаң, үзгәрешләр кертмәсәләр, ел буена шул җитә», – дип әйтүчеләре дә бар.

Электрон системадан баш тартучыларга нишләргә? Министр белдергәнчә, әлегә нибары өч әти-әни генә электрон журнал кулланудан баш тарткан. Республика мәктәпләрендә барлыгы 500 меңнән артык укучы белем ала.

– Электрон журналга керү мөмкинлеге алудан баш тарткан әти-әниләргә, әлеге мәсьәләне хәл итү өчен, сыйныф җитәкчесенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Без Россия Федерациясендә яшибез, кануннарны үтәргә кирәк, – диде Илсур Һадиуллин.

Яңартылган системага керүнең ике юлы бар. Берсе – Россия Дәүләт хезмәтләре аша әти-әни һәм бала теркәлеп. Бу – иң куркынычсыз юл. Хәзерге вакытта барлыгы 100 мең кеше шул рәвешле теркәлгән. Икенчесе – 22 гыйнвардан соң сыйныф җитәкчеләре балага логин һәм пароль бирәчәк. Кыскасы, өлгермәгәннәргә борчылырга кирәкми. Шул ук вакытта белгечләр мошенниклардан сакланырга кирәклеген дә искәртте. Аларның яңалыктан файдаланып, шәхси мәгълүматлар соравы бар. Сак булыгыз! Техник сораулар туганда, **8(843)525-70-99** телефоны буенча «кайнар линия»гә шалтыратырга мөмкин.

Кәгазь журнал җитмиме? Платформаны яңартканчы ук министрлыктан кәгазь журналны, көндәлекне кайтаруны сораучылар булган. Федераль закон буенча, бер үк вакытта электрон һәм кәгазь журналлар алып бару рөхсәт ителми. «Без ул форматтан киттек, аңа нигә кире кайтырга? Укытучыга кәгазь журнал тутыру мәҗбүри түгел», – дип аңлатты Илсур Һадиуллин.

Электрон мәгариф системасын яңарту әйбәт, әмма бу – дистанткa күчүгә бер сәбәп түгелме? Әти-әниләрне мәсьәләнең бу ягы да сагайта.

– Безнең ил бары коронавирус сәбәпле генә дистантка күчәргә мәҗбүр булды. Татарстанда болай укыту 1,5 айга гына сузылды. Шуңа күрә андый күчүләр көтелми. Укытучыны бернинди платформа да алыштыра алмый, – диде республиканың баш педагогы.

Ни өчен яңартылган порталга РФ Дәүләт хезмәтләре порталы аша гына керергә мөмкин? Төбәк дәүләт мәгълүмат системаларын кулланучыларның барысы да ЕСИА (Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы) аша керә. Ул мәгълүматларның куркынычсызлыгын тулысынча тәэмин итә. 2009 елдан бирле бер генә мәгълүматның да читкә киткәне булмаган.

Билгеләр сакланамы? 1 гыйнварга кадәр алынган барлык билгеләр (edu.tatar.ru) дә саклана. Ә быелгылары һәм өй эшләре белән яңа версиядә һәм «Я – школьник», «Дневник. Моя школа» кушымталарында танышырга мөмкин.

Биш көнлек укыту булырмы? Бу сорау да әти-әниләрнең күпчелеген кызыксындыра.

Республикада атнага биш көн генә укый торган мәктәпләр бар. Бу мәсьәләне һәр мәктәп үзе хәл итә. Әмма республика тулысынча болай укытуга күчәргә җыенмый. Министр киләчәктә әти-әниләрнең дүрт көн генә укытуны тәкъдим итәчәгенә дә гаҗәпләнми.

Республика мәктәпләрендә укучылар атнага 23–38 дәрес укый. Ике көн ял итүгә күчкән очракта сәгатьләр тагын да артып китәчәк.

– Балалар көнгә 6–8 дәрес укый. Шуннан соң түгәрәкләргә бара, аннан кайткач, өй эшләрен әзерли. Алар арый, ял да кирәк. Без аларның сәламәтлеге турында уйларга тиеш. Биш көнлек укытуга күчкән төбәкләрдә балалар арасында җинаятьчелек арткан очраклар да бар. Бу – үзе үк ачы тәҗрибә, – диде Илсур Һадиуллин.

Сәрия МИФТАХОВА

«Һәр нәрсәнең чиге бар...»

ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИН ПАРЛАМЕНТНЫҢ БЫЛТЫРГЫ ЭШЕНӘ ЙОМГАК ЯСАДЫ

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, республика парламентының узган елгы эшенә йомгак ясап, бу елга эшләр турында сөйләде. Ул алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының үзенчәлекләре, киләсе сайлауда үз кандидатурасын тәкъдим итү-итмәве, махсус хәрби операциянең кайчан бетәчәге турында әйтте.

«Имтиханны тапшырдык»

Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, узган ел Татарстан өчен генә түгел, гомумән Россия өчен дә, башка күп кенә дәүләтләр өчен дә авыр булды. «Республика имтиханны тапшырды», – дип, башкарган эшкә йомгак ясады парламент җитәкчесе. Моның төп дәлиле буларак, Татарстанда икътисадый күрсәткечләрнең тотрыклы үсүен атады ул.

– Бәлки, кайберәүләр моны җиңел булган дип уйлыйдыр. Юк, ялгышалар. Күп кенә чаралар күрелде, алар авырлыкларны җиңәргә мөмкинлек бирде. Һәрхәлдә, безгә дустанә мөнәсәбәттә булмаган илләрнең Россиягә китергән кыенлыкларын киметә алдык. Елны тынычлыкта, дуслыкта һәм татулыкта үткәрдек, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Ул бу елга кытлыксыз бюджет кабул ителүен дә искәртте.

Узган ел Дәүләт Советында 138 республика законы кабул ителгән, 60тан артык федераль закон проектын тикшергәннәр, шулай ук илнең башка төбәкләреннән 10нан артык закон чыгару тәкъдиме һәм мөрәҗәгатьләр каралган. Безнең депутатлар федераль дәрәҗәдәге 5 закон проекты тәкъдим иткән, аларның 3е буенча эш дәвам итә.

Фәрит Мөхәммәтшин республика парламентының закон кабул итүдә тагын да җаваплырак һәм җентеклерәк эшләвен, шулай ук, гамәлдәге законнарның үтәлүен тикшерүгә игътибар артуын да билгеләп үтте. Камиллекнең чиге юк дигәндәй, сайлаучыларга тагын да якынрак булырга киңәш итте ул.

Сайлауны көткәндә

Билгеле булганча, бу көздә республика парламентын яңадан сайлыйбыз. Фәрит Мөхәммәтшин Дәүләт Советы Рәисе вазыйфасына үз кандидатурасын тәкъдим итәчәкме? Соңгы арада каләм әһелләре парламент җитәкчесе белән очрашкан саен, бу сорауны бирмичә калмый. Хәтерләсәгез, җәй көне Фәрит Мөхәммәтшин тормыш иптәшенең «җитте сиңа» дигән сүзләренә сылтап, китү ихтималын әйтсә, бу юлы алай ук кискен тотмады.

– Мин – җаваплы кеше. Таләп ителсә, ә бүген без катлаулы чор кичерәбез, алга таба да эшләргә туры килүе бар. Тагын бер кат әйтәм: моңа бәйле тәгаен карар юк. Минем әле вәкаләтләрем тәмамланмаган. Көзгә таба уйларбыз. Вакыт күрсәтер, – диде ул.

Яңа срокка тәкъдим ителүдән баш тарткан очракта, яңа варисның исемен әйтүдән дә баш тартты ул. Яшерен-батырын түгел, бу урынга хәзерге вакытта Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары вазыйфасын башкаручы Марат Әхмәтовны димлиләр, дигән имеш-мимешләр йөри.

– Бүген үз варисымны атарга сез мине кем дип уйлыйсыз? Әйтмим, – дип елмаеп җавап бирде Фәрит Мөхәммәтшин. – Марат Әхмәтов – бик яхшы кандидатура, бездә андыйлар күп. Татарстанда бу эшне дәвам иттерә алырлык, әзерлекле кешеләр аз түгел. Ләкин хәтта әзерлекле кешеләрне дә парламент эшенә әзерләргә кирәк. Тормыш шуны таләп итә. Әзерлекле, үз халкын, республикасын, илен яратучы кешеләр кирәк. Борчылмагыз, урын буш калмас.

Аңа кадәр, 15–17 мартта узачак Россия Президенты сайлауларына тукталып, әлеге вазыйфага Владимир Путин кандидатурасын хуплау турында да әйтте ул. «Бернинди басымга да бирелергә кирәкми. Владимир Путин тиешле карарлар кабул итә алуын раслап күрсәтте. Ә Россия бүген сәнәгать продукциясе җитештерү күләме буенча да, тармак күрсәткечләре ягыннан да алдынгылар рәтендә. Владимир Путин эшкә сәләтле һәм илдә яшәүчеләрнең күпчелеге генә түгел, ә безгә дустанә һәм дустанә мөнәсәбәттә булмаган ил җитәкчеләре – хезмәттәшләребез арасында да абруй казанды», – дип, рәсми чараларның берсендә «акылы кеше»дән ишеткән фикерне җиткерде ул.

Үзебезнекеләргә ярдәм

Фәрит Мөхәммәтшин махсус хәрби операция мәсьәләсенә дә аерым тукталды. Республикада солдатларга гына түгел, ә аларның гаилә әгъзаларына да зур ярдәм күрсәтелүен әйтте ул. Былтыр Татарстаннан махсус хәрби операция зонасына гуманитар ярдәм төялгән 133 машина озатканнар.

– Халык ярдәм итәргә әзер. Телевизорны күз яшьләреннән башка карап та булмый. Хәтта әбиләр дә солдатларга оекбашлар бәйли. Бәлки, соңгысын бирәләрдер, әмма кызганмыйлар, – дип, республикада яшәүчеләргә соклануын яшермәде Фәрит Мөхәммәтшин.

Форсаттан файдаланып, быел махсус хәрби операция тәмамлануга өмет бармы, дип тә кызыксындылар парламент җитәкчесеннән.

– Тәгаен көннәрен атарга мин Владимир Жириновский түгел бит, – дип, уенын-чынын бергә кушып әйтте ул.

Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, бүген икътисадый үсеш күрсәткечләрен саклап калу, күпмилләтле һәм күпдинле Татарстанда тынычлыкны тәэмин итү төп бурычларның берсе булып тора. Махсус хәрби операциянең мөмкин кадәр тизрәк тәмамлануына ышаныч белдереп: «Бу бер бездән генә тормый. Дөнья җәмәгатьчелеге дә моның бик күп кешеләрнең үлеменә, предприятиеләр эштән туктауга, гомумән зур кыенлыкларга китерүен аңларга тиеш. Җәмәгатьчелекнең күзе ачылачак дип уйлыйм. Һәр нәрсәнең чиге бар», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Елга нәтиҗә

ҮЗЕҢ БУЛДЫРАСЫ

Кармагын бирәләр, балыгын үзең тотасың! Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының еллык киңәйтелгән утырышында әлеге җөмләне еш кабатладылар. Сүз социаль контракт турында бара. Татарстанның бу уңайдан башкарган эшләрен Мәскәү кунаклары да югары бәяләде. Казанның Бәшир Рәмиев исемендәге IT паркында районнарда социаль килешү төзеп, үз эшен башлаган эшмәкәрләр дә бар иде. Алар арасында табигый ризыклар җитештерүчеләр, бизәнү әйберләре, күннән милли эшләнмәләр ясаучыларны очраттык.

Балтачта яшәүче Гөлсем Зариповага – 24 яшь. Мәктәпне тәмамлагач, Казан технология-дизайн көллиятендә укыган.

– Районга кайткач, үз эшемне башлап җибәрергә булдым. Социаль килешү төзеп булуын белгәч, район Социаль яклау бүлегенә мөрәҗәгать иттем. Дәүләт эш башлар өчен 150 мең сум акча бирде. Моны кире кайтарасы түгел. Шушы акчага иң беренче чималларымны алып, кул эшенә тотындым. Күн эшләнмәләре миңа бик ошый. Соңгы арада халык миллилеккә өстенлек бирә. Шуны исәпкә алып, кул эшләремне бизәкләргә күмдем, – ди Гөлсем.

Республикада 2023 елда Гөлсем кебекләрнең саны 5303кә җиткән. Социаль контракт төзү 2015 елда 9 процентны тәшкил итсә, 2023 елда ул 82 процентка җиткән.

– Кемдер шәхси хуҗалыкта эшли, машина төзәтү станцияләре ачалар, тегү цехларын эшләтеп җибәрәләр, – ди министр. Аның сүзләрен утырышта чыгыш ясаган Актаныш районы башлыгы Ленар Зарипов та хуплады. Актанышта 2023 елда 85 социаль контракт төзелгән.

«Социаль контракт төзеп, мондый кешеләр үзләрен генә фәкыйрьлектән коткарып калмый, башкаларны да эшле итә», – ди Эльмира Зарипова. Республикада фәкыйрьлек дәрәҗәсе исә 2017 елда 7,2 процентны тәшкил итсә, быел 5,5 процентка калган.

– Социаль ярдәм чаралары алучылар саны буенча без аз керемле кешеләрнең кимүен күрәбез. Димәк, кешеләрнең яшәү шартлары яхшыра, – ди министр.

Утырышта социаль тармакка кагылган үзгәрешләр хакында да сөйләделәр. 1 гыйнвардан минималь хезмәт хакы арту, эшсезләр саны кимү, өлкән яшьтәгеләрне яңадан бушлай укыту, гаиләләргә ярдәм чаралары хакында сөйләнелде.

– Республикада уртача хезмәт хакы 59 мең 223 сум тәшкил итә. Татарстан хезмәт хакын түләү буенча Идел буе федераль округында алдынгылыкта, – ди Эльмира Зарипова. – 2024 елда Татарстанда бюджеттан тыш сектор өчен минималь хезмәт хакы күләме 22 мең 20 сум тәшкил итте. Бу – минималь куллану бюджеты кадәр. Без беренче тапкыр республикада минималь хезмәт хакы белән минималь куллану бюджетын тигезли алдык. Ел башыннан яшәү минимумы 13 мең 135 сум булды.

Министр әйтүенчә, Татарстанда 61 социаль ярдәм чарасы бар: 6 федераль һәм 55 республика чарасы. 2023 елда министрлык бюджетының һәр икенче сумы балалы гаиләләргә социаль ярдәм чараларына юнәлтелгән.

– Республикада күпбалалы гаиләләр арту күзәтелә. Соңгы 10 ел эчендә аларның саны, 2 тапкыр артып, 50 мең 200гә җитте, – ди ул.

Эшсезләр саны да кимегән. 2023 елда мәшгульлек хезмәте органнарына эш эзләү максатыннан 31 мең кеше мөрәҗәгать иткән, шуларның 72 проценты эшкә урнаштырылган. Министр әйтүенчә, бүген республикада 49 меңнән артык эш урыны бар. Татарстанда бер эшсезгә 12 вакансия туры килә икән.

Утырышта катнашкан Казан дары заводы генераль директоры Александр Лившиц әйтүенчә, 2024 елда аларга тагын 800 хезмәткәр кирәк булачак. Тик ятмыйлар, районнарга чыгып, эшчеләр эзлиләр. Шартлары да кеше кызыгырлык. Анда эшләүчеләргә махсус хәрби операциядән алып кала торган бронь бирү, армиягә җибәрмичә тору каралган. Уртача хезмәт хакы да аз түгел – 92 мең сум. Директор сүзләренчә, хезмәтенең катлаулылыгына карап, 100–150, хәтта 200 мең сум акча алучылар да бар.

Россия хезмәт һәм социаль яклау министры урынбасары – статс-секретаре Андрей Пудов илкүләм «Демография» проекты кысасында Татарстанда башкарылган эшләргә уңай бәя бирде. Аеруча өлкәннәрне «Озак вакытлы карау» пилот проекты буенча башкарылган эшләргә тукталды. Ул да, социаль контракт төзеп, фәкыйрьлекне киметүне үрнәк итеп куйды.

Шулай ук Дәүләт Думасының Хезмәт, социаль сәясәт һәм ветераннар эшләре комитеты рәисе Ярослав Нилов та, кармак биреп, балык тоттыруның уңышлы эш икәнен әйтте. Россиядә 7 миллионнан артык кеше үзмәшгуль булып теркәлгән, ди.

– Эшсезләргә әнә шулай ярдәм итү яхшы. Без бүген кайчан чираттагы пособиене түләрләр дип көтеп утырмыйча, үз эшен башлаган кешеләр белән таныштык, – диде ул. – Россиядә әле туарга өлгермәгән, анасы карынында яткан бала да социаль түләүгә өметләнә ала. Берәү дә читтә калмый.

Читтә калмау дигәннән, Татарстанның премьер-министр урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә күрсәтелгән ярдәм чараларына тукталды. 2023 елда башкарылган эшләргә уңай бәя биреп, быел да шулай дәвам иттерүне, физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләрне эшкә урнаштыру, аларны яңадан укыту, мәдәни тормышта актив катнашуларын тәэмин итүне оештыруны сорады.

– Гаилә елы уңаеннан демографияне күтәрүне бурыч итеп куябыз, – диде ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Россиянең икенче бәласе

Ленин үлгәнгә бу атна ахырында төгәл 100 ел була. Юлбашчы димәктән, аны XX гасырның төп кешесе дип атаучылар җитәрлек. Ничә гасырлар буе эшчеләр сыйныфын рәхимсез изгән көч – капиталга каршы баш күтәргән, аны Җир йөзеннән себереп түгә алмаса да, ярыйсы ук игә китергән, аңа адәм чырае керткән, дөньяны үзгәрткән зат ул Ленин. Бер үк вакытта аны идеаллаштыру да дөрес түгелдер. Бигрәк тә россияле кавемнәргә. Ни өчен дигәндә, капиталны игә китергәндәге михнәтләр нәкъ менә биредә яшәүчеләр башына ишелде. 70 елдан артыкка сузылган бөек социаль-сәяси тәҗрибә барышында кыенны күбрәк шулар ашады. Әмма…

«Ленин үзе оештырган революциядән соң барысы 6 гына ел яшәп калмаса, Совет илен тагын бер 15–20 ел җитәкләсә, ничек булыр иде икән?» дигән сорау куючылар бар. Яхшы сорау бу. Ихтимал, ул чакта фаҗигаләрнең шактый өлешен урап узу да мөмкин булган булыр иде. Шушы җәһәттән XX гасыр тарихында эз калдырган икенче бер мәгълүм шәхес – Уинстон Черчилль сүзләрен дә искә төшерми булмый: «Россиянең беренче бәласе Ленинның тууы булса, икенчесе – аның үлеме».

Тарихта шарт фигыль, әлбәттә, кулланылмый. Шулай да юлбашчы 54 яше тулмастан бакыйлыкка күчмәгән булса, биредәге тарих ничегрәк язылыр иде икән, дигән сорауны без дә куеп карыйк. Ленин коллективлаштыру дигән көчләүне булдырмас, кече һәм зур террорларны андый дәрәҗәгә җиткермәс иде, дию генә аз кебек. Юлбашчының зирәк акылы, ихтимал, социализм кора башлауга аның җитешсезлекләрен аңлар, ахыр килеп, «чиста социализм» урынына һәр ике стройдан да кирәкне, яхшыны гына алган гибрид җәмгыятьне хуп күрер иде, диясе дә килә. Мондый фаразга аның, ил ачлык-ялангачлыкка бата башлауга, ике дә уйламый, НЭП системасына күчүе дә этәрә. Чыннан да, НЭП – яңа икътисадый сәясәт, ягъни шәхси инициатива, башлангычның өстенлеген, сәүдә генә түгел, җитештерү дигәндә дә алыштыргысызлыгын ул ничек тиз аңлап алса, шулай тиз тормышка да ашырган бит.

Димәк ки, капитализмны бөтенләй бетереп атуның дөрес түгеллеген, аның да уңай яклары барлыгын вакытында аңлау булмаган түгел, булган. Тик 1923 елның маеннан Ленин ныклап авырып китү сәбәпле, ил дилбегәсенең башкалар кулына күчкәнен дә беләбез. Төгәлрәк әйткәндә, ортодоксаль коммунист Сталин кулына. Аның хакында сүз йөрткәндә, ни кызганыч, зирәк акыл сыйфатын бик теләгәндә дә кулланып булмый. Нәтиҗәдә идея хакына миллионнар сукырларча корбан ителеп кенә калмый, «кызыл» икътисадчылар капитализмнан нәрсәдер алу, куллану хакында уйларга да курка.

Гибрид строй дигәндә, коммунистлар партиясе җитәкләгән Кытайда төзелгән капитализмнан да бигрәк, Европа илләренең хәтсезендә күзәтелгән үзенчәлекле «социализм»ны (социализмның классик вариантыннан дөнья күптән баш тартты) күз уңында тотып буладыр. Үткән гасырның 90 нчы елларына чаклы яшәп килгән социалистик илләрнең берсендә дә күзәтелмәгән социаль гаделлекне. Ул – беркайда да күзәтелмәгән яклаулар: үтә дә саллы пенсия, эшсезләргә яхшы пособиеләр, байларга керем күләменә карап салынган прогрессив салым гына түгел, андагы һәр кешегә, социаль статусына карамастан, кеше итеп карау. Классик капитализм белән классик социализмда гомумән дә булмаган нәрсәләр. Ә гибрид стройда – капма-каршы торган ике җәмгыятьнең синтезында алар яралырга сәләтле һәм ярала да. Тарихта шәхеснең роле зурдан: Ленин бабабыз тагын бер егерме ел яшәгән тәкъдирдә, ихтимал, илне гел башка юлдан алып китәр иде.

Ул гына да түгел. Пролетариат юлбашчысы утызынчы еллар азагына кадәр яшәсә, без әле, бәлки, 27 млн корбан китергән, ярты илне хәрабәләр өеменә әверелдергән коточкыч сугышны да күрмәгән булыр идек. Ничек дисезме? Тагын да шул Ленинның зирәк практик акылы сәбәпле, дип әйтик. Ильичның фюрер белән килешү төзеп алдануын, дәүләтен Көнбатыш илләренә каршы куеп, аларны «черек демократияләр» дип атавын никтер күз алдына китереп булмый. Бәс шулай икән, баштан ук АКШ, Бөекбритания, башкалар белән союзда булган СССРга һөҗүм итәргә баш нацист кыяр иде микән? Ихтимал, юк.

Тарихны, андагы вакыйгаларны үзгәртеп булмый, барысы да ничек булган, шулай кала. Дини семинария белеменнән башкасы булмаган, ил белән өч дистә ел буе идарә иткән Сталин, ул майтарганнар да, мифик киләчәк хакына ил күргән барлык михнәтләр дә урынында кала… Ленин да урынында, мавзолейда кала. Үлеменә йөз ел үткәч тә кабергә иңдерелмәгән шәхесләр сирәк. Чөнки ул гел дә дөрес гамәл түгел. Мәет экспонат ролен үтәргә тиеш түгел, җир куенында ятарга тиеш.

Газета укучының Вацлав Гавел дигән кеше – Чехословакиянең, ил икегә бүленгәннән соң Чехиянең Президенты булган, президентлыкка ирешкән бердәнбер язучы, каләм иясе турында ишеткәне бардыр. Шуның әйткәннәрен китерәсе килә: «Коммунизм тарихны туктатты. Хәзер, ул наркоздан уянгач, без барын да яңабаштан башларга мәҗбүр. Тик коммунизмның, аны тормышка ашырырга алынган Ленинның капитализмны, аның белән бергә дөньяны үзгәртүен дә танымый булмый».

М12 БЕЗГӘ НӘРСӘ АЛЫП КИЛДЕ?

МӘСКӘҮ – КАЗАН АРАСЫН УРАП КАЙТКАННАН СОҢ УЙЛАНУЛАР

Владимир Васильев / «Татар-информ»

Гасыр төзелеше

Мәскәү белән Казанны тоташтыручы юл төзелү турында хәбәр килеп ирешкәч тә, без, Кайбыч районы башлыгы урынбасары Рәмис ХӘЯЛИЕВ белән элемтәгә чыгып, фикерләрен сорашкан идек. Хыяллар, чыннан да, тормышка аштымы? Халык бу трассаны ничек кабул итте? Кайчандыр Кырым күпере буйлап Владимир Путин артыннан шәхси машинасында йөреп кайткан Рәмис Хәялиев Яңа ел бәйрәмендә гаиләсе белән яңа юлны да сынап карарга булдылар. Ул безгә юлда күргәннәрен, белгәннәрен, халыктан ишеткәннәрен, уй-фикерләрен җиткерде.

Тарафдарлар да, каршылар да күп

– Мин – чыннан да, М12 трассасының тарафдары. Аңлашыла ки, «Каршылар да бармыни?» дигән сорау туар. Халыкны аптырашта калдырган беренче сорау: «Ничек инде, моңарчы матур гына йөргән юллар кинәт кенә түләүлегә әйләнде?» Бу җәһәттән мин икътисадый яктан үзем белгән исәп-хисапны китереп үтәм. Мәгълүматлардан күренгәнчә, яңа салынган трассаның һәр километры 1 млрд сум тирәсенә төште. Мәскәү белән Казан арасы 800 км икәнен күздә тотсак, гомуми сумма 1 трлн сумга якын килеп чыга. Юл шәхси-дәүләти партнерлык рәвешендә салынды. Күпчелеге – шәхси акча. Аңлашыла ки, бу сумма кайчан да булса хуҗаларына кайтарылырга тиеш. Ул гына да түгел. М11 трассасының, Кырым күперенең дә шул ук ысул белән төзелгәнен исәпкә алсак, М12 түләүле булудан туктатылмаячак, кергән акча башка юллар салу өчен тотылачак, дип фаразлана.

Миңа үз гомеремдә Мәскәү белән Казан арасында күп йөрергә туры килде. Нәрсәләр генә күрмәдем мин анда. Шул исәптән бишәр-алтышар сәгать «бөке»ләрдә дә тордым. М7 трассасы, чыннан да, мораль яктан күптән инде искерде. Яңа юл бик кирәк иде. Яңасы буенча йөрергә теләмәгән кеше, рәхәтләнеп, үзенчә, М7 трассасы буенча җилдерә ала.

Тарихи юл

Әйтергә кирәк, минем тарафдарлыгым күбрәк тарих белән кызыксынуга бәйле. Гомер-гомергә мин бу хакта уйланып, үземчә теорияләр корып яшәдем. Кайбыч ул Татарстанның көнбатышында урнашкан, Мәскәүне көнбатыш өлкәләр белән тоташтыра торган төп юл нәкъ менә шушы территориядән үтәргә тиеш иде. Әмма чынбарлык башкачарак булды: М7 трассасы, Түбән Новгород аша китеп, Идел яры буйлап салынды. Ә бит Кайбыч Иван Грозный Казанны басып алганчы да, аннан соң да Мәскәү юлына урнашкан. Бөек Ватан сугышы вакытында хәтта немецларны да шушы яктан килер дип фаразлаганнар, окоплар казытканнар. Ат юллары да шушыннан булган, чөнки ул – иң туры һәм иң кыска юл. Яңа трасса безне читләтеп узса, мин моны тарихи гаделсезлек дип кабул иткән булыр идем. Бәхеткә, алай булмады. Үзем уйлап тапкан теориягә туры килеп, Татарстан аша узучы 140 км юлның 60ы Кайбыч районы аша салынды.

Сыналу

1 гыйнвар бәйрәм көн булгангамы, юл бөтенләй буш иде. Аның каравы тынычлап кына күзәтеп барырга бик уңай булды.

Күзәтүләремнән чыгып, шуны әйтә алам: трассаның Татарстан өлешен иң яхшыларыннан дип билгеләп үтәргә була.

Татарстанны үтеп, Чувашия Республикасы буйлап киттек. Аларга якынча 100 км юл тия. Шул аралыкта бары тик бер заправка урнашкан. Әйтергә кирәк, бу проблема әлегә шоферларны трасса буйлап озата бара. Әмма мәсьәлә тиз арада хәл ителер дип уйлыйм. Буш урыннар күп калдырылган чөнки. Ягулык салу станцияләре урнашкан урыннар «күпфункцияле зона» дип атала. Анда комплекслы корылмалар төзелү күздә тотыла. Заправка – аның бер өлеше генә. Безнең Кайбыч районында да төзелде бу зона. «Татнефть» бүләге. Юлның ике ягында да туклану пунктлары, ял итү урыннары, хәтта мөселманнарга намаз уку бүлмәләре дә каралган.

Трасса Чабаксарга да, Түбән Новгородка да керми. Зур шәһәрләр читтә кала. Монысы кечкенә шәһәрләрне үстерү программасына бәйле. Башта Сергач шәһәрен үттек. Икенче пункт – Арзамас шәһәре. Аңа юл Мәскәү ягыннан ачылган иде. Ул трасса күпмедер эшләде. Шуңа күрә монда ягулык салу проблемасы да юк, бүтән уңайлыклар да бар.

Владимир өлкәсендә мин бик күңелле күренеш белән очраштым: тагын бер «Татнефть» заправкасы очрады. Бездәгечә бик матур корылган. Булсын дип, киләчәк өчен дип эшләгәннәр. Кешеләрне татар халык ашлары белән сыйлыйлар. Машинаны куеп, рәхәтләнеп ял итәргә була.

3 гыйнвар көнне кайтырга чыктык. Монда хәлләр киресенчә иде инде. Яңа гына эшли башлау сәбәпле, зоналарда хезмәт күрсәтүчеләр эшкә өйрәнеп җитмәгән әле. Шуңа күрә этеш-төртеш китте. Соңрак, берничә көн үткәч сорашкан идем. Трасса гадәти хәленә әйләнеп калды, диделәр. Димәк, бәйрәм яңа юл өчен сыналу көннәре булган.

Әйтергә кирәк, уңайлыкларны да әледән-әле уйлап чыгара торалар. Мәсәлән, мин алгы пыялага транспондер куйдырдым. Түләүле юлда йөргән өчен акча автомат рәвештә алына дигән сүз бу. Әйләнеп кайтыр өчен 4100 сум тирәсе түләргә туры килде. Казанга кадәр 300 сумнан артыграк була. Транспондер белән 1600 балл эшләгәнмен. Димәк, икенче баруда ташлама булачак.

Тизлек чиксез булмасын

Трассада без гадәтләнгән мөмкинлекләрнең кайберләре чикләнгән. Юлда туктарга, тиктомалдан басып торырга да ярамый, чөнки түләүле юлның төп идеологиясе – тизлек. Очыш. Монда кеше үзеннән-үзе азартка керә. Дөрес, проектта тизлек сәгатенә 130 км салынган. «Рөхсәт ителгән» 19 километрны кушсак, 149 км булып чыга. Әмма түләүле трасса булгач, кагыйдә бозучыларны тоту өстендә эш алып барылмый. Камера эшли, күрә, әмма җәза бирелми. Мин дә вакыт-вакыт тизлекне булдыра алган кадәр арттырып карадым. Чынлап та, очкан кебек хис барлыкка килә. Әмма бу бик куркыныч. Әйтергә теләгән төп фикерем – тизлекне барыбер чикләргә кирәк. Төнлә йөрүнең дә үз кыенлыклары бар. Проект буенча трасса төн буе яктыртылырга тиеш. Әмма Чувашиянең күп өлешендә әлегә ут янмый.

Нинди дә булса бәлагә тарыган кешене авыр хәлдә калдырмыйлар. Юлның буеннан-буена авария комиссарлары хезмәте эшли. Халык бу хакта белеп бетерми әле. Үзебезнең якта Кайбыч егетләре эшләгәч, алар белән шактый аралашам. Кызганыч, юлда аварияләр булгалый, ватылып калулар да күп. Әмма авария хезмәте бик тиз килеп җитә. Туктап калган машиналарны тарттырып китәләр. «Барысы да бушлай эшләнелә», – дигәч, ышанмаучылар да бар, ди. Бензиннары бетеп, туктап калсалар, заправкага кадәр күпме кирәк, шуны салып җибәрәләр. Ватык машина кузгала алмаса, ян-якларын махсус корылмалар белән әйләндереп, мигалкалар белән саклап торалар. Кызганыч, зур аварияләр дә очраштыргалый. Кайтканда күрдек: бер ханым Кошман белән Мөрәле арасындагы коймага бәрелеп, багананы аударган, түбәнгә тәгәрәп, кыр буенча очып барган. Мондый хәлгә тару өчен, нинди зур тизлек белән барырга кирәклеген үзегез чамалыйсыздыр…

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Йомгак

tatarstan.ru

ҖИТДИ УЕННАР

Татарстанга янә халыкара спорт кайта. Тагын бер айдан Казанда моңарчы күрелмәгән «Киләчәк Уеннары» ярышы узса, җәен 50 илдән спортчылар БРИКС илләре Уеннарына җыелачак. Бу чаралар, кем әйтмешли, башкаларны күрү һәм үзеңне күрсәтү өчен кирәк. Спортның медальләр белән үлчәнмәгән ягы да бар. Анысы турында Татарстан Спорт министрлыгының коллегия утырышында сөйләштеләр.

Узган җомгада Россия вице-премьеры Дмитрий Чернышенко катнашында узган киңәшмәдә Казанда «Киләчәк Уеннары» турнирына әзерлек турында фикер алыштылар. 21 февральдә башланып 3 мартка кадәр дәвам итәчәк әлеге ярышта катнашучылар 21 төрдә чыгыш ясаячак. «Тарихта тәүге тапкыр уздырылучы әлеге турнир иң югары дәрәҗәдә узсын өчен, кулдан килгәннең барысын да эшләячәкбез», – диде утырышта Татарстан Рәисе. Бу атна ахырында исә Казанда буласы тагын бер зур спорт чарасы – БРИКС илләре Уеннарына әзерлек турында сөйләшәчәкләр. Әлеге ярышлар да тәүге мәртәбә оештырыла. Июньдә буласы Уеннарга 50 илдән спортчылар килер дип көтелә.

Республиканың спорт тормышындагы башка хәлләр турында Татарстан Спорт министрлыгының еллык коллегия утырышында сөйләштеләр. Министр Владимир Леонов әйтүенчә, Татарстан Рәисе һәм Хөкүмәт ярдәме белән барлык шәһәр, районнар заманча спорт корылмалары белән тәэмин ителгән. Татарстанда 11820 корылма, шул исәптән 56 Боз сарае, 293 бассейн һәм 21 футбол манежы бар. Халыкның 62,2 проценты даими рәвештә спорт белән шөгыльләнә. 2030 елга әлеге күрсәткечне 75кә җиткерергә ниятлиләр. Хәзерге вакытта республикада спортның 139 төренә игътибар бирелә. 162 спорт мәктәбендә 93,7 мең кеше шөгыльләнә. 953 якташыбыз ил җыелма командалары составына кергән.

Россиянең спорт министры Олег Матыцин Татарстанның спорт тармагы үсешенә зур өлеш керткәнен әйтте һәм республиканы федераль министрлыкның ышанычлы партнеры дип атады. Аның сүзләренә караганда, Татарстан профессиональ һәм массакүләм спортны үстерү буенча үрнәк күрсәтә. Республикада спорт дәүләт сәясәтенең өстенлекле юнәлеше булып тора. «Татарстанда спорт – яуланган медальләр генә түгел, бу – беренче чиратта, тотрыклы үсешнең нигезе», – диде ул.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, Татарстанда физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүнең әһәмиятен аңлап эшлиләр. Республикада спорт инфраструктурасын үстерүгә зур игътибар бирелә. «2024 елга республика бюджетын формалаштырып, без әлеге тармакны алга таба үстерү, тренерларга хезмәт хакын арттыру, инфраструктураны үстерү программаларын гамәлгә ашыруны дәвам иттерү өчен яхшы саннарны яклый алдык, – диде Фәрит Мөхәммәтшин бу тармакка тотылган чыгымнар турында. – Безнең бурыч – физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен мөмкин кадәр күбрәк кешене җәлеп итү. Безнең өчен профессиональ спортта югары казанышлар гына түгел, ә кешеләрнең сәламәтлеге дә мөһим».

Коллегия утырышында катнашучылардан спорт дөньясында иң танылган кеше, өч мәртәбә Олимпия чемпионы, Россиянең Чаңгы узышлары федерациясе президенты Елена Вяльбе Татарстанга берничә көнгә килгән иде. Билгеле булганча, Казанның Тынычлык бистәсендә чаңгы узышлары буенча Россия Кубогының бишенче этабы ярышлары узды. Анысы да тәүге мәртәбә. «Республикада өлкән спортчыларга гына түгел, балаларга да зур игътибар бирелә. Мине шунысы сөендерә. Узган ел сезгә балалар ярышына килгән идем. Анда бер яшь категориясендә генә дә 400ләп бала катнашты. Бу – якын арада сездә Олимпия чемпионнары үсеп чыгачак дигән сүз. Үзегездә туган һәм үскән чемпионнар! Алар өчен сездә барлык шартлар да бар», – диде ул коллегия утырышында. Елена Вяльбе ярышлар вакытында да мактау сүзләрен кызганмады. Казан читендәге чаңгы һәм биатлон комплексын илнең «чаңгы үзәге» дип атады. Биредә зур чаралар уздыру нияте барлыгын әйтте.

Россия Кубогының бишенче этабында төп герой булып өч мәртәбә Олимпия чемпионы Александр Большунов танылды. Ул үзе катнашкан өч ярышта да финишка беренче булып килде һәм рәттән яуланган җиңүләр санын 15кә җиткерде. Татарстан спортчылары да сөендерде. Безнекеләр ике көмеш һәм бер бронза медаль отты. Ольга Сергеева спринт ярышында икенче урынны алды. Шул ук төрдә ир-егетләр арасында Сергей Ардашев – икенче, Иван Горбунов өченче булды. «Без аларның уңышларына бик шат. Бу бит Олимпия Уеннарына тиң ярыш булды», – диде Татарстанның Чаңгы узышлары федерациясе президенты Илшат Фәрдиев.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

ФЕРМЕР ХӘЛЕН... ТУРИСТ БЕЛЕР

Фермерларга, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүчеләргә туристларны кабул итәргә рөхсәт бирмәкчеләр. Дәүләт Думасына шул хакта закон проектын тәкъдим иткәннәр.

ru.freepik.com

Әлеге тәкъдим нигезендә авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүче барлык хуҗалыклар да туристларны урнаштыру өчен кунак йортлары төзү мөмкинлегенә ия булачак. Бу аларга өстәмә табыш китереп, җитештергән продукциясен популярлаштыруда булышса, туристларга авыл сулышын яхшырак тоярга форсат булыр иде. Һәрхәлдә, закон проектын әзерләүчеләрнең максаты шул. Әлеге тәкъдим фермерлар өчен нинди дә булса таләпләр яки чикләүләр кертүне күздә тотмый.

Фермерлар фикере

Балык Бистәсе

Олеся КАРАГАНОВА, балыкчылык белән шөгыльләнә:
– Без балык тоту һәм эшкәртү белән шөгыльләнәбез. Бер караганда, бу тәкъдим безгә әллә ни кагылмый да кебек. Тик шунысы хак: авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү территорияләрендә йортлар бик кирәк. Чөнки еш кына, җитештерү эше фермер яшәгән җирдән ераграк урнашкан була. Барып йөрүдә кыенлыклар туарга мөмкин. Андый йортларга ихтыяҗ барлыгын шәхсән беләм.

Хуҗалыкларда кунаклар да кабул итәргә рөхсәт итсәләр, чынлап та, бик яхшы булыр иде ул. Дәүләткә – салым, безгә өстәмә керем чыганагы бит бу. Моның ярдәмендә туристлар санын да бермә-бер арттырырга мөмкин, фермерлар да кунаклар өчен программаны яңартып, баетып, үзгәртеп торачак.

Дөрес, без дә туристларны кабул итәбез. Әмма төн куну шарты белән түгел. Балык заводына экскурсия оештырабыз. Моннан тыш тематик остаханәләр, шул исәптән гастрономик мастер-класслар да тәкъдим итәбез, Балык Бистәсе тарихы турында сөйлибез.

Кайбыч

Рушан САЙРАНОВ, тавык үрчетү белән шөгыльләнә:
– Бик әйбәт тәкъдим бу! Бу мәсьәләне күптән күзәтеп киләбез, мөрәҗәгатьләребез дә, моңа бәйле сораулар да булды. Дөресен әйткәндә, авыл хуҗалыгын үстерүгә бәйле барлык проектларны да хуплыйбыз инде без. Аларның берсе дә зыянга булырга тиеш түгел.

Туристларны кабул итүгә кире әйләнеп кайтсак, бик күп фермерларга үзләренә дә кызыклы юнәлеш бит ул. Хәзерге вакытта авыл туризмы бик популяр. Аеруча гаиләле кешеләргә кызыклы да, эчтәлекле дә программалар тәкъдим итәргә мөмкин. Мондый кызыклы программалар булдыру юнәлешендә үземнең дә фикерләрем бар. Әлегә ныклап тотынган гына юк. Дәүләт тарафыннан чынлап та ярдәм булса, тәкъдим отышлы булырга охшап тора.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Сан

• **2022** елда Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы авыл туризмын үстерү проектларына конкурс игълан иткән иде. Нәтиҗәдә Россиянең **63** төбәгеннән **223** гариза килгән. Сайлап алудан соң шуларның **73**енә **3–10** миллион сум грант бирелгән.
• **2023** елда грант откан агротуризм объектларына **250** меңгә якын кеше килгән. Авыл хуҗалыгы министрлыгы фаразынча, алдагы елларда авыллардагы кызыклы маршрутларга ихтыяҗ арта гына барачак.

Хәтер

ЗӨЛФИЯ АВЗАЛОВА-НИГЪМӘТҖАНОВА:

«БҮГЕН АВЫЗЫМНЫ ЯПСАМ, ИРТӘГӘ ОНЫТАЧАКЛАР»

Хәтерлибез, яратабыз... 15 гыйнварда татар халкының яраткан җырчысы, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, Тукай премиясе лауреаты Әлфия Авзалованың тууына 91 ел тулды. Аның җырлары бүген дә сәхнәдә яши, ә исемен оныттырмаучы кызы – Зөлфиясе: «Көч булганда, эшлибез әле», – ди. Зөлфия АВЗАЛОВА-НИГЪМӘТҖАНОВА белән без кыска хәтер, тагын бер Әлфия һәм сагыну турында сөйләштек.

:: Халык хәтере мәңгелек, дисәләр дә, соңгы арада шактый кыскарды кебек ул. Әлфия Авзалованы бүген хәтерлиләрме?
– Аллага шөкер, хәтерлиләр. Әни үлгәч, бер ел тирәсе аның турында бик сагынып, юксынып сөйләделәр. Аннары ничектер оныта башладылар. Мин моны сиздем, аның турында гел искә төшереп тормасам, бөтенләй онытылуы бар, дип уйладым. Гәрчә аны онытырга мөмкин булмаса да. Әлфия Авзалованы тыңлап үскәннәр аны хәтерли, сагына. Ә иң сөендергәне – яшь җырчыларның әнинең хит җырларын башкаруы. Җырлары яши икән, Әлфия Авзалова да яши.

Ничек кенә булса да, мин аны онытырга ирек бирмим. Бүген авызымны ябам икән, иртәгә онытачаклар. Көч булганда, дәрт булганда, эшлибез әле.

:: Инде шактый эшләнгән дә бит...
– Аллага шөкер. Әни турында өч телдә – татарча, русча һәм инглизчә китап чыгардык. Инглиз телендәгесен читтә яшәүче татарларга, китапханәләр, мәдәният йортлары, мәктәпләргә тараттык. Балалар ниндидер Том Сойер турында укыганчы, үзебезнең шәхесләр турында укысын, дидек.

2018 елдан бирле Әлфия Авзалова истәлегенә зур фестиваль уздырабыз, быел өченчесе үтте. Шөкер, лауреатларыбыз – бик талантлы яшьләр. Ел саен гран-при иялрен дә билгелибез. Беренче фестивальдә – бу исемгә Илнар Миранов белән Актаныш кызы Лилия Хөсәенова, икенче фестивальдә – Алмас Хөсәенов, ә быелгысында Татьяна Ефремова лаек булды. Гран-при ияләренә генә түгел, гомумән, катнашучыларга ничек тә ярдәм итәргә тырышабыз. Минем лауреатлар белән гастрольләргә чыгу хыялы да бар. Ул талантларны халык күрергә, ишетергә тиеш!

:: Татьяна Ефремова, димәктән, аны Әлфия Авзаловага охшаталар. Сезгә ничек тоела?
– Таняны беренче тапкыр әни исән чакта, «Әлиф» спектаклендә күрдем. Ул чакта ук аның тавышы таң калдырды. Ниндидер аңлатып булмаслык үзенчәлек бар анда. Охшатсыннар, чагыштырсыннар. Ләкин аларны чагыштырырлык түгел.

:: Гомумән, Әлфия Авзалова белән чагыштырырлык тавыш күренәме бүген?
– Әлегә күренми. Мин генә түгел, безнең конкурстагы жюри әгъзалары да килешер бу фикер белән. Ләкин бераз эзләнсәң, тагын бер Әлфия бардыр ул. Бәлки, ниндидер бер авылда яшәп ятадыр. Миңа миңа шулай тоела. Ул кызчыкка бераз гына булышып җибәрсәң, сәхнәдә балкыр иде кебек...

Әни музыка училищесында ике генә ел укыган. Чын мәгънәсендә халык җырчысыннан опера җырчысы «әвәли» башлагач, училище директоры: «Кызым, кит», – дигән аңа. Шуңа киткән.

:: Ә фестивальдә менә шундый үзешчән башкаручылар өчен аерым номинация булдырырга теләмисезме? Бәлки, яңа Әлфияләр күренә башлар иде.
– Безнең фестиваль, беренче чиратта, профессионаллар һәм ярымпрофессионаллар, ягъни музыка мәктәпләрендә, көллиятләрдә укучылар өчен. Ләкин безгә үзешчәннәр дә килә. Нигезләмәгә карап тормыйча, аларны да тыңлыйбыз. Араларында бик талантлары була. Безнең бурыч – аларга ярдәм итү. Безнең яшь чикләве дә 12дән 35 яшькә кадәр бит. Кечкенә талантларны үстерәсе иде. Хәлдән килгәнчә, билгеле. Шөкер, хөкүмәт ташламый, үзебез дә тырышабыз. Әйе, кайсыбер фондларга бик яхшы булышалардыр. Әмма без булганына канәгать.

:: Тагын нинди эшләр ниятләп йөрисез?
– Камал театрында Әлфия Авзаловага багышланган спектакль әзерләнә. Кем куячагы әлегә сер булып калсын. Әнинең җырларыннан караоке-диск туплыйбыз. Бик матур итеп эшләргә исәп. Иганәчебез бар. Планнар күп. Үземә бер ай ял биргән идем. Балаларым, ирем янында Америкада әле мин. Тиздән Казаныма кайтам да эшкә тотынам, Алла боерса.

Әни кебек

:: Тышкы яктан сез елдан-ел әниегезгә охшыйсыз. Холык буенча да шулаймы?

«Иртән торып, көзгегә карыйм да, нәкъ әни бит мин, дип уйлап куям», – ди Зөлфия Авзалова-Нигъмәтҗанова.

– Мин үзем дә шаккатам. Иртән торып, көзгегә карыйм да, нәкъ әни бит мин, дип уйлап куям. Ирем дә шулай ди. Әни гел: «Мин ике мәртәбә кияүдә булдым, ике ирдән ике төрле бала таптым. Олы кызым – фәрештә, бәләкәй кызым – җен. Нәкъ үземә охшаган», – дия торган иде *(көлә)*. Өстенә баскан. Апам бик тыныч, мин бөтен нәрсәне пыр туздырам. Нәкъ әни мәрхүмкәем кебек... Аңа охшагач, мин бик бәхетле. Яхшы кеше иде ул.

Сагындыра... Әйтәләр бит әле, вакыт узган саен җиңелрәк була, дип. Дөрес түгел. Бөтенләй дә дөрес түгел. Вакыт узган саен, әниеңне башка беркайчан да күрмәячәгеңне аңлыйсың. Теге дөньяда очрашсаң гына... Ә ул дөнья бармы икән? Моны да беркем төгәл генә әйтә алмый...

:: Әниегез төшкә керәме?
– Алты ел ярымга елга дүрт мәртәбә керде. Шунысы гаҗәп: өчесе фестиваль алдыннан булды. Беренче фестивальдә без Алмас Хөсәенов белән «Синең өчен» җырын җырлаган идек. Шуның алдыннан төш күрәм: әни бәрхет күлмәктән җырлап басып тора. Кулында – җыр сүзләре. «Синең өчен»не җырлаганын беләм, ләкин сүзләрен аңлап булмый. «Әни, сүзләре кулыңда бит, карап җырла», – дип тә карыйм үзем... Соңгы тапкыр ике ай чамасы элек, шулай ук фестиваль алдыннан керде. Ул көнне өйгә бик соң кайттым. Аш бүлмәсендә калган ашны контейнерга тутырдым, кәстрүленә су салып куйдым. Җебегәч, иртән юып куярмын, мин әйтәм. Шул төнне, дөресрәге, иртәнге якта төшемә әни керде. Аш бүлмәсе белән коридор арасында басып тора. Йөзе күренми, ләкин чәчләре, куллары – анык. «Нишләп торасың?» – дим. Карасам, теге мин калдырган кәстрүлне юып, ап-ак сөлгегә киптерергә каплап куйган. Табак-савытны шулай киптерергә ярата иде ул. Уянып киттем дә тизрәк кәстрүл юарга чыктым. Оят булды...

:: Әлфия апа үлгәннән соң, аның турында сез белмәгән фактлар килеп чыкмадымы?
– Әни бик ачык кеше иде, бөтен нәрсәне безгә сөйләде. Аның турында белмәгән нәрсә калмады бугай. Башкалар белмәгәннәрне әйтә алмыйм, аларын Аллаһы Тәгалә белә дә, без беләбез.

P.S. 15 гыйнварда Әлфия Авзалованың туган көне булса, 16 гыйнварда – Илһам Шакировның арабыздан китүенә 5 ел. Бүген әлеге ике легенда җирләнгән Яңа Татар бистәсе зиратында, каберләренә чәчәк салып, җырчыларны искә алдылар.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

Соклану

Күбрәк булса иде синдәйләр

Һәркем үзенең эшен яратып, профессиональ дәрәҗәдә җиренә җиткереп башкарганда гына тормышыбыз ямьлерәк, киләчәгебез ышанычлы булачак. Андый кешеләр бар, әмма күбрәк булсын иде! Сүзем – шундыйларның берсе – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Алсу Хәкимова турында.

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә 1997 елда килә ул. Алсу – филармония музее мөдире. Беренче эш көненнән башлап чирек гасырдан артык вакыт узган...

Ул Алексеевск районы Олы Тигәнәле авылында яшәгән Люция һәм Әсгать Хәлиловларның өченче балалары булып дөньяга килә. Абыйлары Ринат белән Илдарның көтеп алынган сеңелләре. Берсе – колхозчы, берсе математика укытучысы булган бабалары Бөек Ватан сугышы кырында һәлак булалар. Гомере буе авылдашларына балитәкле матур күлмәкләр тегүче Исламия әбисе дә, Алсуга бер яшь булганда, бакыйлыкка күчә. Әтисе ягыннан Нәсимә дәү әнисе белән бергә яшиләр алар. Аның намаз укулары, Коръән сүрәләрен яттан көйләп сөйләүләре әле дә ишетелә сыман Алсуга...

Эш сөючән булып үсәләр Хәлиловларның балалары. Әтисенең урманчы булып эшләгән елларын да бик яхшы хәтерли Алсу. Аның арбалы матаена утырып, урманга баруларын сагынып искә ала ул: «Кайда чикләвек үскәнен, печәнлек, җиләкле аланнарны, мәтрүшкәләр үскән урыннарны бик яхшы белә иде әти. Урман эчендә урнашкан колхоз умарталыгын хәтерлим. Әти белән шунда Мансур абый янына кереп, бал белән мәтрүшкәле чәй эчмичә китми идек. Әти үзе дә гомере буе умарталар тотты. Шуларга карап күңеленә тынычлык ала иде...» Ә әнисе башта авылда балалар бакчасында эшләгән, соңрак машиналар заправкасында эшен дәвам иткән. «Ул гомере буе китаплар укырга яратты, хәзер дә газета-журналлар алдыра, бер хәрефен дә калдырмый игътибар белән укып чыга», – ди Алсу ханым.

1998 елда мин аны беренче тапкыр күргән идем: озын чәчле, зифа буйлы, зәвык белән киенгән мөлаем кыз Алсу. Вакыт узулары сизелми дә... Инде олы кызлары Айзилә дә – Казан федераль университеты студенты, Әмир дә – 8 нче сыйныф укучысы.

Ире Айдар Хәкимов белән танышуын Алсу болай искә ала: «2004 елның көзе иде. Беренче тапкыр күрүем филармониядә, кадрлар бүлеге бүлмәсендә булды. Башта, аны күргәч, яңа кеше эшкә килә икән, дип уйлап куйганым истә калган. Ә ул күптәннән ансамбльнең баянчысы булып эшли икән. Сәхнәдә артистлар костюмнардан бөтенесе дә бертөрле кебек күренә бит... Озак та үтми, «Пирамида» концертлар залына миңа режиссер ярдәмчесе булып барырга туры килде. Ул концертка ансамбльнең дә чыгышлары кергән иде. Концерттан соң без Айдар белән сөйләшеп китеп, аралаша башладык. Язмыштыр, өч айдан соң өйләнешеп тә куйдык. Гаилә коруыбызга да тиздән егерме ел була икән инде. Сизелмәде дә...»

Хәзерге көндә Татарстанның атказанган артисты Айдар Хәкимов – Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбленең баянисты һәм музыка җитәкчеләренең берсе. Аңлашыла инде, балалар тәрбияләү күбрәк Алсу җилкәсенә төшә. «Аллага шөкер, әти-әниләребез бик булыштылар», – ди ул.

Алсуның филармония артистлары белән аралашканын еш күрдем. Барысына да бертигез дәрәҗәдә игътибарлы, барысы белән дә уртак тел таба ул. Моңа кешене өйрәтеп тә буладыр бәлки. Әмма мин аны күп еллар беләм һәм ялгышмыйча әйтә алам: ерак 1990 нчы елларда ук шундый иде ул. Каян бу сыйфат? Бәлки, кемнән дип сорарга кирәктер? Ә Алсу, мөлаем елмаеп, җавабын кайтара: «Күңел ничек таләп итә, булдыра алганча шулай эшлимдер инде. Кечкенә чакта дәү әнием дә: «Синең белән сөйләшү рәхәт, кызым», – ди торган иде».

Музейга килеп йөргән, әле үз көчендә булган артистлар белән аралашу гына түгел, ә алар авырганда өйләренә, хастаханәләргә барып хәлләрен белешергә, аларны соңгы юлга озатканда байтак эшләрдә катнашырга, соңрак каберләрен зиярәт кылуны оештырырга да туры килә аңа. «Болары да – музей мөдире вазыйфаларымы?» – дип сорадым бервакытны. «Бу эшләр, әлбәттә, Татар дәүләт филармониясе җитәкчелеге тарафыннан хәерхаһлы булып эшләнелә. Гомумән, элек-электән филармония коллективы дус-тату гаилә кебек бердәм эшли бездә. 2014 елда «Илһамият» ветераннар клубы оешкач, сәхнә ветераннары белән аралашу тагын да җанланып китте. Хастаханәгә хәлләрен белергә баруым да Ходай ризалыгы өчен, күңел таләп иткәнгә эшләнелә торгандыр. Бу гамәл күп кешегә хастыр, гадәти хәлдер дип уйлыйм», – дигән иде Алсу.

Филармония оештырган концерт-кичәләр алдыннан фойеда күргәзмәләр оештыру, фотогалереяны яңа фотолар белән тулыландырып тору, филармония музеена экспонатлар туплау һәм башка бик күп, бик күп эшләр... Үз җае, үз агымы белән бара, ди ул.

«Кайда гына булсам да, күңелемдә бер теләк, – ди Алсу ханым. – Халкыбыз бер-берсенә мәрхәмәтле, дус булса иде». Амин, шулай булсын! Һәрберебезгә уртак теләк инде бу. Һәм... күбрәк булсын иде синдәйләр, Алсу!

Фәрдия СӘФӘРГАЛИЕВА

ҖИРДӘН КӨЧ АЛЫП

Авыл җаны

Авылга кайткан саен, сул як күршедә атлар уйнаклавын, печән төргәкләренең рәт-рәт өелеп торуын күреп, күзем ял итеп килә. Мин күрергә теләгән авыл инде бу. Татар авылында ат булырга тиеш бит инде!

Күршеләребезнең яшь гаилә булуы тагын да сөендерә. Берсе балалар бакчасына, икенчесе мәктәпкә йөрүче кызлар үстерә Гөлназ белән Ленар Исмәгыйлевләр. Гөлназ – Актаныш кызы, Яңа Чишмәдә инглиз теле укыта. Ленар – кечкенәдән күз алдыбызда үскән тыйнак, акыллы, булдыклы егет. Әниләре Тәнзилә апа, яшьли тол калып, ике баланы аякка бастырды.

«Нишләп авылда калырга булдың?» – дигән соравымны Ленарга да бирәм.

– Армиядән хезмәт итеп кайтканда, авылда бергә үскән минем яшьтәге дус егетләр, кызлар – бөтенесе дә шәһәрдә иделәр инде. Ул вакытта «мода» шундый иде. Әзрәк ял иткәч, әлбәттә, мин дә шәһәр ягын караштыргалый башладым. Кайда гына эшләп, кайда гына йөрсәм дә, авыл барыбер үзенә тартты. Авыл баласы бит без! Баштагы мәлләрдә, дөресен әйткәндә, авылда яшьләр булмагач, бик күңелсез иде. Кайбер кичләрен урамга чыгып сөйләшеп утырырга да иптәш табып булмый иде, – дип искә ала ул. Авылга кайтуының тагын бер сәбәбе – әнисе. Үзен тәрбияләп үстергән әнисен ялгыз калдырасы килми. Әйе, бәхетле ана ул Тәнзилә апа: оныклар, балалар рәхәтен, рәхмәтен тоеп яши.

«Авылда калдым да бетте түгел шул әле ул. Иң беренче эш кирәк. Аллага шөкер, эш тә килеп чыкты. Эшем район үзәгендәге нефть компаниясенә барып тоташты. Уберенче ел районга йөреп эшлим».

Авылыбызның күзгә күренеп олыгаюын Ленар да борчылып күзәтә.

«Әле ун ел элек колхоз гөрләп торган булса, хәзер ул бетте. Шул тракторчы абыйлар, укытучы апалар күбесе пенсия яшендә. Эш булмагач, күп яшьләр калмады. Яшьләр күп булмагач, яшь гаиләләр саны аз. Яшь гаилә булмагач, балалар аз! Балалар күп булмагач, мәктәпләр ябыла! Бездә генә түгел мондый хәл. Татарстан районнарының күп авыллары шундый хәлдә яши хәзер!» – ди.

Ни өстисең инде монда? Авылда эш юк яшьләргә. Барысы да диярлек районга эшкә йөри. Кайбер гаиләләр үзләренең фермерлык хуҗалыкларын булдырган. Күрше Шахмайда хәлләр яхшырак үзе, яшьләр дә күбрәк. Ул электән үк эчәвылы берләштергән күмәк хуҗалыкның үзәге булып, анда мөмкинлекләр күбрәк булгангадыр бәлки...

Илдә чыпчык үлми, дигәндә дә авылны күздә тотканнардыр. Җир кешесе җирдән көч ала – яши, тереклек итә. «Һәрбер кеше үзенең тормышын үзенчә тарта хәзер. Хәзер бит инде «самообложение»гә акча җыеп, юлларга, су скважиналарына үзебез ремонтлар ясыйбыз. Авылны авылда яшәргә теләгән кеше саклап тора». Мир белән хәл итәбез, диярләр иде элгәрәк. Әле дә кирәк чакта халык бергә тупланып алырга сәләтле ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Татарның атларны яратуы – канында», – ди Ленар Исмәгыйлев.

«Көн сиземлимчә дә үтеп китә!» – диючеләрне хөрмәт итәм мин. Гадәттә, юкны бушка аударып йөрүчеләр түгел алар. Ленарның көне дә шактый тыгыз: «Иртә белән торып, атларны ашатам, анннары эшкә китәм. Эш минем «ненормированный»: ничәдә кайтасын белеп булмый, соң кайткан вакытлар булса, көн бетте дигән сүз. Ничәдә кайтуга карамастан, йорт эшләрен эшләргә, атларны ашатырга кирәк. Алар көтеп тора! Аннан өйдә балалар белән уйныйм. Көн шулай уза да китә».

Ни өчен атлар тотуы белән кызыксынам үзеннән. Гадәттә безнен якта кеше үгезләр асрый. «Атларны башта кызыксыну, хобби өчен үстерә башлаган идем. Шулай әкрен генә кереп кителде. Атларны асрарга җиңелрәк дип уйлыйм мин», – ди үзе. Ә миңа татарның атлар яратуы канындадыр кебек. Ул аны совет чорында беразга онытып кына торгандыр кебек тоела.

Яшьтәшләре авылда бармак белән генә санарлык Ленарның. «Җиде яшь гаилә санадым, ялгышмасам. Бездән өлкәнрәк гаиләләр дә шул чамадыр. Бу зур курсәткеч түгел, соңгы күрсәткеч тә түгел». «Соңгы күрсәткеч түгел», – дию ошады миңа күршемнең. Чүлмәктәге сөткә төшкән тычканнарның тәпи күтәреп батып үлүчесе түгел ул; сөттән май язып, сикереп чыгучысы. Оптимист ягъни.

Шатлык-сөенечләре дә авылга бәйле. «Кайбер җәйге ял көннәрендә урам тулы бала-чага, туганнар, күршеләр кайта шәһәрләрдән, шуңа карап күңел шатлана. Урам гөрләп тора! Авылда шау-шу, тавыш! Движуха!»

Борчуларга килгәндә... «Авылның киләчәге борчый. Ниләр булыр икән ун елдан? Елмаеп торган зур таш йортлар буш калырмы икән? Гөрләп торган авылыбыз белән ниләр булып бетәр икән? Тик шулай да өмет өзелми! Хөкүмәт, берәр программа кертеп, авылларыбызны карый башлар...» – дип өметләнә Ленар.

Лилия ФӘТТАХОВА

ҖАН ТАРТМАСА, БОЗ ТАРТА

Салкын дими, җил дими, ару-талуны белми. Кышын боз өстенә чыгып утырган балыкчылар турында әле сүзебез. Кышкы балык тотуның ни рәхәте бар? Балыкчылар белән кышкы мавыгулары турында сөйләштек.

Рәмзия Мифтахетдинова:

«БАЛЫКНЫ МИН ТОТАМ, ИРЕМ ӘШКӘРТӘ»

Балык тоту стажы – 25 ел

– Энем Марат – балыкка иң беренче алып барган кешем. Беренче баруымда ук җиде судак балыгы тоттым. Хәзер бу шөгыльдән башка яши дә алмыйбыз. 2023 елның 14 декабрендә энем белән яңа кышкы сезонны ачып каййттык. 14 килограммга якын балык тоттык! Кечкенәләрен суга кире җибәрдек инде. Гомумән, тоткан балыкларны саткан юк. Кайчагында үзебезгә дә калмый, өләшеп бетерәбез. Энем белән алабуга балыгын тотарга яратабыз. Бу балыкның чиертүе бик кызык. Кармакка күбрәк судак һәм берш балыклары эләгә.

Минем 15 кармагым, ике зур тартма алдавыч, балансир, раттлин кебек балык тоту өчен кирәк-яраклары бар. Барысын да үзем сатып алам. Кибеткә кереп, нәрсә дә булса алмыйча чыксам, күңелем булмый.

Үземне кышкы балыкчы дип саныйм. Махсус киемнәрем дә бар. Әйтик, аяк киеме минус 75 градус суыкка кадәр чыдый! Өс киемнәрем дә һава торышына яраклаштырылган. Салкыннан курыкмыйбыз, –32 градус суыкта да балыкка барганыбыз булды.

Һава торышы үзгәреше балыкка да тәэсир итә бит ул. Балыкка тотрыклы атмосфера басымы, болытлы көн кирәк. Кинәт җил чыгу, суыту ошамый. Гыйнвар – мартта балык актив булмый.

Шунысы да бар: балыкны тотарга гына яратам. Эшкәртү эшен исә иремә тапшырам. Балыктан уха да пешерәбез, кыздырып та ашыйбыз.

Айназ Борһанов:

«ТОТКАН БАЛЫКНЫ КҮЧТӘНӘЧ ИТЕП БИРӘМ»

Балык тоту стажы – 8 ел

– Минем әниемнең әтисе – бабай – балыкчы. Хәзер миңа 13 яшь. 3–4 яшьлек чагымнан бирле аңа ияреп балыкка йөрим. Үсә-үсә, бу мавыгу үземә дә бик ошый башлады. Бабай янына кайтам дип, каникулны көтеп алам хәзер. Әле менә Яңа ел ялларында Арчада идем, бабай белән балыкка йөрдек.

Балык тоту өчен барлык кирәк-яракларны сатып алдым. Боз тишә торган бур, махсус сумка, кармаклар...

Кышкы балыкчылыкка килгәндә, суык бер дә сизелми. Үзенчә бер рәхәт ул. Балыкны судан тартып чыгару азарт өсти дип әйтимме... Балык тотканда бик тыныч. Бабай белән сөйләшеп, төрле планнар корып утырабыз.

Әти ягыннан әби-бабам янына – Арча районының Урта Аты авылына кайткач та балыкка йөргәлим. Әмма анда балык бик юк, вак ташбашлар гына. Арчада исә зурлары да эләккәли. Туганнар минем балык алып кайтканны көтеп тора. Күчтәнәч итеп аларга бирәм.

Виктор Полянсков:

«БАЛЫК ТОТАМ, ДИП ТҮГЕЛ, ЯЛ ИТӘМ, ДИП ЙӨРИМ»

Балык тоту стажы – 6 ел

– Кышкы балыкчылыкның чын фанаты димәс идем мин үземне. Өстенлекне җәйгә бирәм. Әмма кышын да өйдә тик ятасы килми. Балык тоту – төп шөгыльлем. Башка балыкчылар кебек еш бармасам да, йөрим. Бу бит – бертөрле кызыксынулары булган кешеләр белән очрашу, буш вакытны файдалы итеп уздыру да.

Әлләни зур балыклар тоттым дип мактана алмыйм. Чабак, бель, корбан балыгын тотам. Балык тотканда максатым – зурысын тоту түгел, ә табигать кочагында ял итү, улым, дусларым белән аралашу. Яз айларында 10 килограммга кадәр балык тотканым бар.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Чистайның психик тайпылышлары булган гражданнар өчен интернат-йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең палата шәфкать туташы **Бәдретдинова** Рәмзия Ранат кызы; күпьеллык намуслы хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Хезмәтне саклау төбәкара ассоциациясе рәисе, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының сәламәтлек саклау һәм демография комиссиясе әгъзасы **Габдрахманов** Фәнил Исхак улы; күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе һәм Федераль таможня хезмәтенең Идел буе таможня идарәсе Татарстан таможнясы Казан аэропорты таможня посты башлыгы, таможня хезмәте полковнигы **Гәрәев** Мирзанур Миргазәм улы; республикада музей эшен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Тәтеш ягы тарихы музее» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Понедельникова** Наталья Геннадьевна; пенсия белән тәэмин итү системасын камилләштерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге бюджет бүлеге башлыгы урынбасары **Потапова** Эльмира Исмәгыйль кызы, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге Казан шәһәренең Киров районындагы клиентлар белән эшләү хезмәте (бүлек хокукында) җитәкчесе **Сафина** Гүзәл Илдар кызы; халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Арча районының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе әйдәүче инспекторы **Сабирова** Гүзәл Фәрит кызы; республикада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм нәтиҗәле эшчәнлеге өчен «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры урынбасары **Әдиятуллина** Дилара Шамил кызы; күпьеллык намуслы хезмәтләре, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүләре өчен Россия Федерациясе Тикшерү комитеты Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсенең икенче контроль-тикшерү бүлеге җитәкчесе урынбасары – беренче бүлекчә (тикшерү органнарын контрольдә тоту) җитәкчесе, юстиция полковнигы **Алборов** Антон Геннадьевич, Татарстан Республикасы прокуратурасы җинаять эшләре-суд идарәсенең дәүләт гаепләүчеләре бүлеге өлкән прокуроры **Зарипова** Ольга Владимировна; сатып алулар өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга зур өлеш кертүе һәм нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары **Баһаутдинов** Искәндәр Гыймади улы; республикада гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесенең гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге башлыгы **Дианова** Лариса Михайловна; республиканың энергетика тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыяте капиталь төзелеш идарәсенең инвестицияләрне планлаштыру һәм хисап бүлеге башлыгы **Мостафин** Әнвәр Әнәс улы; һөнәри эшчәнлекләре казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе төбәк законнары һәм муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү мәсьәләләре бүлеге башлыгы урынбасары **Пашкова** Майя Александровна, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының норматив хокукый актларны теркәү һәм хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы **Слепнева** Эльмира Илсур кызы Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Мобиль ТелеСистемалар» гавами акционер җәмгыятенең Татарстан Республикасындагы филиалы челтәрне үстерү бүлегенең челтәрне планлаштыру һәм оптимальләштерү функциональ төркеме эксперты **Вильд** Денис Александровичка, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы **Кремлев** Дмитрий Александровичка **«Татарстан Республикасының атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре» дигән** мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Рәисе администрациясе, әнисе

ПРИВАЛОВА Валентина Тимофеевна

вафат булу сәбәпле, Казан (Идел буе) федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе директоры Привалов Игорь Анатольевичның авыр кайгысын уртаклаша.

Белдерү

АО «Татэнергосбыт» уведомляет, что в соответствии со Стандартами раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии, утвержденными постановлением Правительства РФ от 21.01.2004 № 24, на официальном сайте АО «Татэнергосбыт» tatenergosbyt.ru размещена информация о ценах и объемах электрической энергии каждого свободного договора купли-продажи электрической энергии, зарегистрированного гарантирующим поставщиком на оптовом рынке в отношении его зоны деятельности, а также величина корректировки составляющей предельного уровня нерегулируемых цен при учете свободного договора купли-продажи электрической энергии, определяемая коммерческим оператором оптового рынка в соответствии с договором о присоединении к торговой системе оптового рынка.

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

БӘЯЛӘМӘ № 1

Гражданка Н.М. Яценконың мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы үзара бәйле нигезләмәләрнең конституционлыгын тикшерү турында

Татарстан Республикасы Конституция советы, Конституция советы Рәисе И.И. Гыйләҗев, Конституция Советы әгъзалары Р.Ф. Гафаров, Э.М. Мостафина белән берлектә, «Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 2 өлешенә, 11 статьясына таянып, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы үзара бәйле нигезләмәләрнең конституциячеллеген тикшерү турындагы мәсьәләне карады.

Гражданка Н.М. Яценконың мөрәҗәгате эшне карауга сәбәп булды.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән норматив-хокукый нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы мәсьәләдә ачыкланган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Татарстан Республикасы Конституция советы, конституция советы әгъзасы – докладчы Э.М. Мостафина мәгълүматларын, утырышта катнашучыларның – гражданка Н.М. Яценконың, карауга чыгарылган Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларын бастырган орган вәкиле – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы урынбасары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе социаль законнар бүлеге мөдире Д.И. Мәхмүтовның аңлатмаларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны тикшергәннән соң

ТҮБӘНДӘГЕЛӘРНЕ БИЛГЕЛӘДЕ:

1. Татарстан Республикасы Конституция советына гражданка Н.М. Яценко «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы (алга таба– 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы (алга таба – 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) белән үзенең конституциячел хокуклары бозылуга шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Пенсиясе «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән яки 2018 елның 31 декабренә әлеге федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килгән, мөрәҗәгать итү көненә айлык уртача керемнәре күләме 20 000 сумнан артмаган хезмәт ветераннарына, Татарстан Республикасының 63-ТРЗ номерлы Законының 5 статьясы нигезендә, социаль ярдәм чаралары күрсәтелә, шул исәптән торак өчен түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидия бирелә.

Татарстан Республикасы 100-ТРЗ номерлы Законының 2 статьясы эчтәлеге буенча, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы нигезләмәләре (Татарстан Республикасының 100-ТРЗ номерлы Законы редакциясендә) социаль ярдәм чаралары 2016 елның 1 гыйнварына кадәр билгеләнгән хезмәт ветераннарына кагылмый.

Гражданка Н.М. Яценко, үз таләпләрен дәлилләп, 1990 елдан «Хезмәт ветераны» исеменә лаек булган гражданнар категориясенә каравын, әмма айлык акчалата түләү һәм коммуналь түләүләр буенча субсидияләр бирү рәвешендәге социаль ярдәм чараларын 2023 елның гыйнварыннан гына ала башлавын әйтә. Мөрәҗәгать итүче билгеләп үткәнчә, 2023 елның маеннан бу түләүләр туктатылган, чөнки ул алган пенсия күләме 20 000 сумнан артып киткән (тигезләп әйткәндә, 22 766 сум тәшкил иткән). Хәзерге вакытта ул социаль ярдәм чараларыннан мәхрүм ителгән, чөнки пенсиясе күләме 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясында билгеләнгән күләмнән 2 776 сумга арткан.

Гражданка Н.М. Яценко фикеренчә, күрсәтелгән Законның 5 статьясы, Татарстан Республикасының 100-ТРЗ номерлы Законының 2 статьясы нигезендә, шулай килеп чыга: 2016 елның 1 гыйнварына кадәр социаль ярдәм чараларын алган хезмәт ветераннары, кереме күләменә карамастан, бу хокукны саклап кала. Шул ук вакытта 2016 елның 1 гыйнварына кадәр «Хезмәт ветераны» исеменә лаек булган, әмма социаль ярдәм чараларын алмаган гражданнар әлеге хокуктан мәхрүм ителгән булып чыга.

Шулай итеп, мөрәҗәгать итүче билгеләп үткәнчә, төбәк закон чыгаручысы социаль ярдәм чараларын алу өчен төп шарт итеп «социаль ярдәм чараларын фактта алу вакытын» билгеләгән. Ләкин, аның фикеренчә, юридик яктан әһәмиятле шарт булып «Хезмәт ветераны» исемен бирү вакыты тора, ул үзе 1990 елда ук социаль ярдәм чараларын алу хокукына ия булган, әмма аларны үзенә бәйсез сәбәпләр аркасында алмыйча килгән.

Гражданка Н.М. Яценко раславынча, тормыш тәҗрибәсе шуны күрсәтә: 2016 елның 1 гыйнварына кадәр социаль ярдәм чараларын рәсмиләштергән хезмәт ветераннары, пенсиясе күләменә карамастан (хәтта «зур» пенсия алган очракта да) аларны алуны дәвам итә. Шул ук вакытта ул, 1990 елдан бирле хезмәт ветераны булып торса да, үзенә социаль ярдәм чаралары 2016 елның 1 гыйнварына кадәр бирелмәгәнгә күрә генә бу хокуктан мәхрүм ителгән.

Мөрәҗәгать итүче шундый нәтиҗәгә килгән: төбәк законнары, хезмәт ветераннарына ташламалар билгеләгәндә, бары тик социаль ярдәм чараларын рәсмиләштерү вакытына гына исәпкә алып, «Хезмәт ветераны» исемен бирү датасына игътибар итмәгән. Ул шулай ук, әлеге исемне бирү чоры – бу мәсьәләдә бик кирәкле һәм әһәмиятле, нәкъ менә шушы көннән социаль ярдәм чараларын алу хокукы барлыкка килергә тиеш, дигән катгый фикердә тора.

Гражданка Н.М. Яценко раславынча, кешеләрне болай аеру гаделсезлеккә, аның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез кысуга китерә, шулай ук пенсияләре аның пенсиясеннән күп тапкыр артыграк булган һәм озак вакыт дәвамында социаль ярдәм чараларыннан файдаланган башка социаль ярдәм чаралары алучылар белән чагыштырганда кимсетү булып тора.

Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, хәзерге вакытта 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы буенча, социаль ярдәм чараларын мөрәҗәгать итү датасына айлык уртача кереме, индексацияне исәпкә алып, 30 009 сум 15 тиеннән артмаган хезмәт ветераннары алырга мөмкин.

Гражданка Н.М. Яценко, югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Конституция советыннан «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясын һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 22, 27-31, 54, 58 статьяларына туры килмәвен тануны сорый.

«Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 2 өлеше нигезендә, Конституция советы бәяләмә чыгарганда, карауга чыгарылган норматив-хокукый актның туры мәгънәсен бәяли. Татарстан Республикасы Конституция советы норматив-хокукый актны караганда, шулай ук аңа рәсми аңлатма һәм башка аңлатма белән бирелгән яки аны тормышта куллану тәҗрибәсе биргән мәгънәне бәяли. Конституция Советы бәяләмәне мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча гына чыгара, ә норматив-хокукый актны караганда, аның мөрәҗәгатьтә Конституциягә туры килү-килмәве шик астына алынган өлешенә карата гына чыгара. Татарстан Республикасы Конституция советы бәяләмә чыгарганда, мөрәҗәгатьтә бәян ителгән нигезләр һәм дәлилләрне исәпкә алмый.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Конституция советы каравының предметы булып фәкать 2016 елның 1 гыйнварына кадәр күрсәтелгән чараларны алучылар өчен генә, айлык уртача керемнәре күләменә карамастан, хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын саклауны күздә тоткан «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясының һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясының үзара бәйле нигезләмәләре тора.

2. Әлеге бәяләмәдә карала торган Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары хезмәт ветераннарына, Россия Федерациясе Конституциясе (72 статьясының 1 өлешендәге «ж» пункты) нигезендә, Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында булган социаль яклау чараларының бер өлеше булып торучы социаль ярдәм чаралары исемлеген һәм аларны күрсәтү шартларын билгели Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы предметлар буенча федераль законнар һәм алар нигезендә Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив-хокукый актлары чыгарыла. Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив-хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясының 2 һәм 5 өлешләре).

Татарстан Республикасы Конституция суды 2006 елның 6 декабрендәге 22-П номерлы, 2007 елның 22 февралендәге 23-П номерлы, 2009 елның 6 маендагы 34-П номерлы, 2010 елның 25 февралендәге 38-П номерлы, 2010 елның 29 июнендәге 40-П номерлы карарларында шундый нәтиҗәгә килде: республика закон чыгаручылары, гражданнарның аерым категорияләренә, шул исәптән хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын хокукый җайга салуны гамәлгә ашырып, Россия Федерациясе Конституциясендә билгеләнгән Россия Федерациясе һәм аның субъектларының вәкаләтләре чикләрен аерудан чыгып, үз карамагындагы Татарстан Республикасы Конституциясенең 54 (2 өлеше) һәм 75 (2 пункты) статьялары нигезендәге вәкаләтләрен хәл кылган.

Шулай итеп, шул исәптән, хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чаралары исемлеген һәм аларны күрсәтү шартларын җайга салучы «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын кабул итү Татарстан Республикасы Дәүләт Советы компетенциясенә керә.

3. Татарстан Республикасы Конституциясенең 13 статья нигезендә, 54 статьясындагы беренче өлеше белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасында, сәясәте кешенең лаеклы тормышын һәм иркле үсешен тәэмин итүче шартлар тудыруга юнәлдерелгән социаль дәүләт буларак, һәркемгә, яше буенча. авырып китү, инвалидка әйләнү, туендыручысын югалту очрагында, балаларны тәрбияләү өчен һәм закон белән билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституциясенең 54 статьясындагы беренче өлешенең мәгънәсе буенча социаль тәэминат, Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда һәм күләмнәрдә, социаль ярдәм чараларын күрсәтүне үз эченә ала.

Карауга чыгарылган законнарга тиешле конституцион-хокукый бәя Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позицияләре ягыннан хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын күрсәтү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салучы федераль законнарның норматив-хокукый актлары белән системалы бәйләнештә бирелергә мөмкин.

3.1. Россия Федерациясендә ветераннарны социаль яклауның хокукый гарантияләре, аларны лаеклы тормыш, актив эшчәнлек белән, җәмгыятьтә ихтирам һәм хөрмәт белән тәэмин итү шартларын булдыру максатында, «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән.

Әлеге Федераль законның 10, 22 статьялары нигезендә, хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чаралары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив-хокукый актлары белән билгеләнеп, Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләре булып тора.

63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителгән вакытта гамәлдә булган «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.3 статьясындагы 2 пунктының 24 пунктчасы (алга таба – 184-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә, хезмәт ветераннарына социаль ярдәм мәсьәләләрен хәл итү, уртак карамактагы предметлар буенча, әлеге органнар тарафыннан мөстәкыйль рәвештә, Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары хисабына (федераль бюджеттан субвенцияләрдән тыш), Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләренә кертелгән.

Шулай итеп, федераль закон нигезләмәләрендә күздә тотылганча, Россия Федерациясе субъектлары, Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамактагы эшләр буенча социаль яклауны үз эченә алган вәкаләтләре чикләрендә, хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын билгеләү өлкәсендә мөнәсәбәтләргә үзләре хокукый яктан җайга салуны билгеләүгә, шул исәптән, Россия Федерациясенең тиешле субъектлары бюджетлары акчалары хисабына, күрсәтелгән категориягә социаль ярдәм чараларын бирү нигезләрен, төрләрен, формаларын, шартларын һәм тәртибен законнар белән билгеләүгә хокуклы.

Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә социаль ярдәм чаралары «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән. Әлеге Законның 5 статьясында (1 пункты) «Хезмәт ветераны» исеменә ия булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары исемлеге, шулай ук аларны бирү шартлары билгеләнгән. Татарстан Республикасының 63-ТРЗ номерлы Законының 5 статьясының беренче редакциясендә пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе тәэмин итүе турында» федераль законнар нигезендә пенсияләре билгеләнгән хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларының күрсәтелүе күздә тотылган.

Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 28 июнендәге Бюджет юлламасы нигезләмәләрен тормышка ашыру максатыннан чыгып, Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 27 декабрендәге 2553-р номерлы боерыгы белән расланган «Гражданнарга социаль ярдәм» Россия Федерациясе дәүләт программасында билгеләнгәнчә, гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чаралары системасын үстерү, Россия Федерациясе субъектларының хокукларын тагын да киңәйтү нигезендә, дәүләт социаль ярдәменә мохтаҗ гражданнарның категорияләрен билгеләү һәм социаль ярдәм чараларына мохтаҗлык критерийларын билгеләү юлы белән гамәлгә ашырылырга тиеш.

Әлеге федераль норматив нигезләмәләрне үтәү максатында, 2013 елның 21 декабрендәге 371-ФЗ номерлы федераль закон белән 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.3 статьясы 2.1 пункты өстәлгән. Аның нигезендә, Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм мәсьәләләрен хәл иткәндә, үз вәкаләтләре чикләрендә, Россия Федерациясе субъектының законнары һәм башка норматив-хокукый актлары белән мохтаҗлык критерийларын билгеләү хокукы бирелгән. Шул ук вакытта гражданнарның аерым категорияләре өчен социаль ярдәм һәм социаль ярдәмнең өстәмә чараларын билгеләү вәкаләтләрен финанслау Россия Федерациясе субъектының бурычы булып тормый, ул мөмкин булган очракта гына гамәлгә ашырыла һәм федераль бюджеттан өстәмә акча бүлеп бирүгә нигез булып тормый (184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.3-1 статьясының дүртенче өлеше,).

Федераль закон чыгаручы «Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законда (44 статьясының 1 өлешендәге 49 пунктчасы һәм 8 өлеше, 48 статьясының 4 өлеше) да хезмәт ветераннарын социаль ярдәм чаралары белән тәэмин итү мәсьәләсен хәл кылуга карата шундый ук алымны саклап калган.

Россия Федерациясе Конституция суды күп тапкырлар билгеләп үткәнчә, федераль закон чыгаручы, гражданнарның теге яки бу категорияләрен социаль яклауга юнәлдерелгән конкрет чараларны һәм Россия Федерациясе субъектларының бу чараларны гамәлгә ашыруда катнашу дәрәҗәсен, формаларын билгеләп, тиешле затларны социаль яклау чаралары белән тәэмин итүнең Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан гамәлгә ашырылуын билгеләү генә түгел, ә мондый чаралар белән тәэмин итү буенча чыгым йөкләмәләрен Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләренә кертүгә дә хокуклы. Россия Федерациясе субъектының закон чыгаручысы исә, социаль яклау өлкәсендә бирелгән вәкаләтләрен гамәлгә ашырып, үзе теләгәнчә эш итү буенча киң мөмкинлекләргә ия, һәм үз акчалары хисабына гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чараларын күрсәтү төрләрен һәм шартларын мөстәкыйль билгеләргә хокуклы. Әмма хокукый яктан тиешле җайга салуны кертәндә һәм үзгәрткәндә, ул дискриминациянең теләсә нинди формаларыннан саклауны гарантияләүче гаделлек һәм тигезлек принципларын үтәргә тиеш. Бу исә, башка нәрсәләрдән тыш, бер үк категориягә караган кешеләрнең хокукларында объектив һәм акылга нигезләнгән аклануга ия булмаган мондый аермаларны тыюны (бер үк төрле яки охшаш хәлләрдә калган кешеләргә карата төрлечә мөгамәләне тыю) аңлата. Гражданнарның аерым категорияләре тарафыннан теге яки бу хокукны гамәлгә ашыру шартларындагы аермалар, һәрхәлдә, һавадан алынган булмаска тиеш, һәм алар нигезле булганда, конституцион әһәмиятле максатларда гына рөхсәт ителә, ә бу максатларга ирешү өчен кулланыла торган хокукый чаралар аларга ярашлы булырга тиеш (Россия Федерациясе Конституциясенең преамбуласы; 19 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләре; 55 статьясындагы 3 өлеше) (2022 елның 31 маендагы 22-П номерлы карар).

Татарстан Республикасы закон чыгаручысы, Россия Федерациясе субъектларына хезмәт ветераннарын социаль яклау өлкәсендә бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырып, шулай ук адреслылык принцибын исәпкә алып, 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» яки 2018 елның 31 декабренә әлеге федераль законнар нигезендә каралган пенсия билгеләү шартларына туры килеп, уртача айлык кереме 20 000 сумнан артмаган хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын күрсәтүне күздә тоткан үзгәрешләрне керткән (63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы). 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә, хезмәт ветераннарына социаль ярдәм күрсәтүнең телгә алып үтелгән яңа шартлары әлеге закон үз көченә кергәнче үзләренә социаль ярдәм чаралары билгеләнгән хезмәт ветераннарына кагылмый.

63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясының, 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы белән үзара бәйләнештә, турыдан-туры мәгънәсеннән чыгып, 2016 елның 1 гыйнварына кадәр социаль ярдәм чаралары алган хезмәт ветераннарына, керемнәренең күләменә карамастан, бу хокук сакланып кала.

Россия Федерациясе Конституция суды 2019 елның 26 сентябрендәге 2238-О номерлы Билгеләмәсендә билгеләп үткәнчә, хезмәт ветераннарына социаль ярдәм күрсәтү чараларын күрсәткәндә, дифференциацияләүнең объектив критерие буларак, айлык уртача керемнең 20 000 сумнан артмавы турындагы закон шарты әлеге категориягә караган гражданнарның конституцион хокукларын кысуга юнәлдерелгән хокукый җайга салу буларак карала алмый.

Татарстан Республикасы закон чыгаручысы, хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын бирүне хокукый җайга салуны үзгәртеп, Татарстан Республикасы бюджетының чынбарлыктагы мөмкинлекләреннән чыгып, шулай ук социаль ярдәмнең адреслылыгын арттыру максатында, гражданнарга социаль ярдәм өлкәсендә федераль закон нигезләмәләренә таянып эш иткән, шуның белән 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы үз көченә кергәнче әлеге чараларны алган хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын саклап калган. Шул ук вакытта бу закон белән 2016 елның 1 гыйнварыннан социаль ярдәмнең тиешле чараларын алучылар даирәсе ачыкланган. Аерым алганда, мондыйларга пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән яки 2018 елның 31 декабренә әлеге федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килеп, айлык уртача керемнәре 20 000 сумнан артмаган хезмәт ветераннары кертелгән.

Мондый хокукый җайга салу республика закон чыгаручысы тарафыннан хезмәт ветераннарын социаль яклау системасын реформалаштыру кысасында башкарылды һәм, беренчедән, хезмәт ветераннарын социаль ярдәм чаралары белән тәэмин итү буенча дәүләтнең үз өстенә алган йөкләмәләрен үтәүгә, икенчедән, гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүнең адреслылыгын көчәйтүгә һәм, гражданнарның мохтаҗлык критерийләре нигезендә, Татарстан Республикасы бюджетыннан мондый ярдәм күрсәтүнең максималь дәрәҗәдәге социаль нәтиҗәсенә ирешүгә юнәлдерелгән.

Карауга чыгарылган нормаларның эчтәлеге 2016 елның 1 гыйнварына кадәр әлеге чараларны алучы хезмәт ветераннарына социаль ярдәм күрсәтүнең элеккеге шартларын саклап калуга юнәлдерелгән. Бу үзе үк дәүләтнең социаль сәясәтенең конституцион әһәмиятле максатларына туры килә – ә аның өчен гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәмнең өстәмә чараларын бирү социаль яклау өлкәсендә иң мөһим бурычларның берсе булып тора (Россия Федерациясе Конституциясенең преамбуласы һәм 7 статьясы) – шулай ук Россия Федерациясе Конституциясеннән килеп чыккан гаделлек һәм гражданнарның законга, дәүләт гамәлләренә ышанычын саклау принципларына туры килә.

Россия Федерациясе Конституция суды үз карарларында күп тапкырлар Россия Федерациясе субъекты закон чыгаручысының гражданнарга социаль ярдәм чараларын бирүнең элек билгеләнгән кагыйдәләрен үзгәртүе гражданнарның законга һәм дәүләтнең хокукый билгеләнешне күздә тоткан гамәлләренә ышанычын саклау принцибы үтәлсен өчен гамәлгә ашырылырга тиешлегенә, хокукый җайга салуның акылга нигезләнгән тотрыклылыгын саклауны, гамәлдәге нормалар системасына һавадан алынган үзгәрешләр кертүгә юл куелмаячагына һәм закон чыгару сәясәтенең, шул исәптән социаль өлкәдә, бертөрлелегенә, хокукый мөнәсәбәтләрдә катнашучыларның үз-үзләрен тотышы нәтиҗәләрен алдан ук аңлап-белеп тора алсыннар өчен, үзләренең рәсми танылган статусының, хокукларының үзгәртелмәвенә, аларны дәүләтнең тиешенчә яклавына, ягъни гамәлдәге законнар нигезендә үзләренә бирелгән хокукларының хакимият тарафыннан хөрмәт ителәчәгенә һәм гамәлгә ашырылачагына ышана алырлык дәрәҗәдә гамәлгә ашырылырга тиешлеген күрсәтте (2001 елның 24 маендагы 8-П номерлы https://login.consultant.ru/link/?req=doc&base=LAW&n=31809 8-П, 2002 елның 19 июнендәге 11-П номерлы, 2004 елның 23 апрелендәге 9-П номерлы, 2022 елның 31 маендагы 22-П номерлы карарлар һ. б.; 2003 елның 4 декабрендәге 415-О номерлы, 2005 елның 15 февралендәге № 17-О номерлы, 2005 елның 1 декабрендәге 521-О номерлы билгеләмәләр һ.б.).

Карауга чыгарылган Татарстан Республикасы законнарының нигезләмәләрендә билгеләнгән хокукый җайга салу хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чаралары исемлеген һәм аларны бирү шартларын күздә тота, һәм ул үзеннән-үзе гражданнарның конституцион хокукларын чикләү һәм тигезлекнең конституцион принцибыннан килеп чыгучы таләпләрне бозу буларак бәяләнә алмый, чөнки ул Татарстан Республикасы закон чыгаручысының Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте Законнар чыгару (вәкиллекле) органына бирелгән, үзенең хокукый хәленә, шул исәптән федераль нормалар нигезендә билгеләнгән хокукый хәленә туры килүче статусы компетенциясе чикләрендә өстенлекле вәкаләтләрен тормышка ашыруның конституцион-хокукый механизмына ярашлы конституцион легаль дискрециясе булып тора.

Социаль ярдәм чараларын күрсәтүне дәүләт социаль сәясәтенең төп юнәлешләренең берсе итеп тану сәбәпле, дәүләт хакимияте эшчәнлеге, шул исәптән аның закон чыгару функциясе, әлеге сәясәтнең Конституциядә билгеләнгән өстенлекле булып торучы максатлары нигезендә тормышка ашырыла, өстенлекле максат исә республика закон чыгаручысына, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләреннән килеп чыгучы хосусый-җәмәгать мәнфәгатьләренең конституцион-хокукый балансын – үз сәясәтен гражданнарның социаль гаделлеге һәм юридик тигезлеге конституцион принципларында гамәлгә ашыручы, кеше һәм гражданның югары кыйммәт булган хокукларын һәм ирекләрен хөрмәт итүче һәм яклаучы Татарстан Республикасы дәүләтчелегенең хокукый табигатенә туры килгән хокукый балансын үтәү таләпләренә таянып, әлеге максатларга ярашлы хокукый җайга салуны билгеләү һәм аны гуманистик модернизация юнәлеше буенча үстерүне һәм камилләштерүне гамәлгә ашыру бурычы куя.

Татарстан Республикасы Конституция советы, югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шундый нәтиҗәгә килде: «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы һәм 2016 елның 1 гыйнварына кадәр социаль ярдәм чараларын алып килгән хезмәт ветераннары өчен генә үзләренең айлык уртача керемenә бәйсез рәвештә социаль ярдәм чараларын саклап калуны күздә тоткан «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясының үзара бәйле нигезләмәләре белән билгеләнгән хокукый җайга салу Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан, социаль-икътисадый үсешнең әлеге этабында республиканың финанс мөмкинлекләреннән һәм башка мөмкинлекләреннән чыгып, гражданнарның билгеле бер категорияләрен социаль яклау гарантияләрен тормышка ашыру ягыннан дәүләтнең конституцион бурычларын тәэмин итү зарурилыгы белән билгеләнгән дискрецион вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән, һәм ул гражданнарның конституцион хокукларын, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституцион хокукларын бозу буларак карала алмый, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә.

Мөрәҗәгать итүченең 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көченә кергәнче хезмәт ветераны буларак социаль ярдәм чараларын алу хокукыннан файдаланмавының сәбәпләрен билгеләү исә факттагы хәлләрне тикшерү һәм өйрәнүгә бәйле, ә бу «Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законы буенча Татарстан Республикасы Конституция советы вәкаләтләренә керми. Шул ук вакытта шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: «Хезмәт ветераны» исемен бирү процедурасы да, социаль ярдәм чараларын бирү тәртибе дә гариза тапшыруны күздә тота.

3.2. Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгатенең хезмәт ветеранының уртача айлык кереме күләмен билгеләү өлешенә килгәндә, индексацияне исәпкә алып, аның социаль ярдәм чараларын алу хокукына ия булу-булмавы мөһим. Татарстан Республикасы Конституция советы шуңа игътибарын юнәлтә: Татарстан Республикасы законында, индексацияне исәпкә алып, уртача айлык керем күләмен исәпләү механизмын билгеләү карауга чыгарылган гражданнар категориясе буенча социаль ярдәм чараларын алучылар даирәсен киңәйтәчәк һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнарга китерәчәк.

Чынлыкта гражданка Н.М. Яценко хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын күрсәтү шартларына үзгәрешләр кертү турында мәсьәләне күтәргән. Ә бу закон чыгаручы компетенциясенә керә. Ул, Россия Федерациясе Конституция суды карарларында күп тапкырлар билгеләп үтелгәнчә, дәүләтнең үсешенең билгеле бер этабында финанс-икътисади мөмкинлекләрне исәпкә алып һәм шул ук вакытта гаделлекнең, тигезлекнең, шулай ук гражданнарның хокукларының тотрыклылыгының һәм гарантияләнүенең конституцион принципларын үтәп, әлеге өлкәдә үзе билгеләгән җайга салуны үзгәртүгә хокуклы (2015 елның 22 декабрендәге 2999-О номерлы билгеләмә).

Шулай итеп, карауга чыгарылган закон нормаларын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип тану Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, үзенең дискрецион вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысасында, гражданнарның социаль ярдәм чараларына, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгатендә күтәрелгән айлык уртача керем күләмен – хезмәт ветераннарына социаль ярдәм күрсәтү шуңа бәйле –индексацияләү турында мәсьәлә буенча конституцион хокукын гамәлгә ашыруны тәэмин итүне хокукый җайга салуны камилләштерү мөмкинлеген карарга комачауламый.

Татарстан Республикасы Конституция советы, Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 2 өлеше, 11 статьясы, Татарстан Республикасы Конституция Советы Регламентының 32-35 статьялары нигезендә,

БӘЯЛӘМӘ ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы һәм 2016 елның 1 гыйнварына кадәр социаль ярдәм чараларын алып килгән хезмәт ветераннары өчен генә үзләренең айлык уртача керемenә бәйсез рәвештә социаль ярдәм чараларын саклап калуны күздә тоткан «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясының үзара бәйле нигезләмәләрне Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга, чөнки алар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан, социаль-икътисадый үсешнең әлеге этабында республиканың финанс мөмкинлекләреннән һәм башка мөмкинлекләреннән чыгып, гражданнарның билгеле бер категорияләрен социаль яклау гарантияләрен тормышка ашыру ягыннан дәүләтнең конституцион бурычларын тәэмин итү зарурилыгы белән билгеләнгән дискрецион вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән.

2. Әлеге бәяләмәне «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Конституция советының «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Конституция советы Рәисе И.И. Гыйләҗев

Татарстан Республикасы
Конституция советы әгъзалары Р.Ф. Гафаров, Э.М. Мостафина

Приложение
к постановлению Центральной избирательной
комиссии Республики Татарстан
от 15 января 2024 г. № 34/248

Сообщение
Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан
о приеме предложений по кандидатуре члена избирательной
комиссии с правом решающего голоса в состав
территориальной избирательной комиссии
города Азнакаево Республики Татарстан
на вакантное место

В связи с прекращением полномочий члена территориальной избирательной комиссии города Азнакаево Республики Татарстан с правом решающего голоса, руководствуясь статьями 22, 26 и 29 Федерального закона «Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации», статьями 11, 15 и 18 Избирательного кодекса Республики Татарстан, Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан объявляет прием предложений по кандидатуре для назначения члена территориальной избирательной комиссии города Азнакаево Республики Татарстан с правом решающего голоса.

Прием документов осуществляется в период с 16 января 2024 года по 22 января 2024 года по рабочим дням с 09.00 до 18.00 часов (перерыв на обед с 12.00 до 13.00 часов), по адресу: ул. Батурина, д.7Б, г. Казань, 420111 (контактный телефон: 8(843) 292-84-33).

При внесении предложений по кандидатуре в состав территориальной избирательной комиссии на вакантное место необходимо руководствоваться Постановлением Центральной избирательной комиссии Российской Федерации от 15 марта 2023 г. № 111/863-8 «О методических рекомендациях о порядке формирования территориальных, окружных и участковых избирательных комиссий». Образцы необходимых документов размещены на официальном сайте Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

Приложение
к постановлению Центральной избирательной
комиссии Республики Татарстан
от 15 января 2024 г. № 34/249

Сообщение
Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан
о приеме предложений по кандидатуре члена избирательной
комиссии с правом решающего голоса в состав
территориальной избирательной комиссии
Зеленодольского района Республики Татарстан
на вакантное место

В связи с прекращением полномочий члена территориальной избирательной комиссии Зеленодольского района Республики Татарстан с правом решающего голоса, руководствуясь статьями 22, 26 и 29 Федерального закона «Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации», статьями 11, 15 и 18 Избирательного кодекса Республики Татарстан, Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан объявляет прием предложений по кандидатуре для назначения членом территориальной избирательной комиссии Зеленодольского района Республики Татарстан с правом решающего голоса.

Прием документов осуществляется в период с 16 января 2024 года по 22 января 2024 года по рабочим дням с 09.00 до 18.00 часов (перерыв на обед с 12.00 до 13.00 часов), по адресу: ул. Батурина, д.7Б, г. Казань, 420111 (контактный телефон: 8(843) 292-84-33).

При внесении предложений по кандидатуре в состав территориальной избирательной комиссии на вакантное место необходимо руководствоваться Постановлением Центральной избирательной комиссии Российской Федерации от 15 марта 2023 г. № 111/863-8 «О методических рекомендациях о порядке формирования территориальных, окружных и участковых избирательных комиссий». Образцы необходимых документов размещены на официальном сайте Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

Приложение
к постановлению Центральной избирательной
комиссии Республики Татарстан
от 15 января 2024 г. № 34/250

Сообщение
Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан
о приеме предложений по кандидатуре члена избирательной
комиссии с правом решающего голоса в состав
территориальной избирательной комиссии
Менделеевского района Республики Татарстан
на вакантное место

В связи с прекращением полномочий члена территориальной избирательной комиссии Менделеевского района Республики Татарстан с правом решающего голоса, руководствуясь статьями 22, 26 и 29 Федерального закона «Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации», статьями 11, 15 и 18 Избирательного кодекса Республики Татарстан, Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан объявляет прием предложений по кандидатуре для назначения члена территориальной избирательной комиссии Менделеевского района Республики Татарстан с правом решающего голоса.

Прием документов осуществляется в период с 16 января 2024 года по 22 января 2024 года по рабочим дням с 09.00 до 18.00 часов (перерыв на обед с 12.00 до 13.00 часов), по адресу: ул. Батурина, д.7Б, г. Казань, 420111 (контактный телефон: 8(843) 292-84-33).

При внесении предложений по кандидатуре в состав территориальной избирательной комиссии на вакантное место необходимо руководствоваться Постановлением Центральной избирательной комиссии Российской Федерации от 15 марта 2023 г. № 111/863-8 «О методических рекомендациях о порядке формирования территориальных, окружных и участковых избирательных комиссий». Образцы необходимых документов размещены на официальном сайте Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

Приложение
к постановлению Центральной избирательной
комиссии Республики Татарстан
от 15 января 2024 г. № 34/251

Сообщение
Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан
о приеме предложений по кандидатурам членов избирательной
комиссии с правом решающего голоса в состав
территориальной избирательной комиссии
Пестречинского района Республики Татарстан
на вакантные места

В связи с прекращением полномочий двух членов территориальной избирательной комиссии Пестречинского района Республики Татарстан с правом решающего голоса, руководствуясь статьями 22, 26 и 29 Федерального закона «Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации», статьями 11, 15 и 18 Избирательного кодекса Республики Татарстан, Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан объявляет прием предложений по кандидатурам для назначения членов территориальной избирательной комиссии Пестречинского района Республики Татарстан с правом решающего голоса.

Прием документов осуществляется в период с 16 января 2024 года по 22 января 2024 года по рабочим дням с 09.00 до 18.00 часов (перерыв на обед с 12.00 до 13.00 часов), по адресу: ул. Батурина, д.7Б, г. Казань, 420111 (контактный телефон: 8(843) 292-84-33).

При внесении предложений по кандидатурам в состав территориальной избирательной комиссии на вакантное место необходимо руководствоваться Постановлением Центральной избирательной комиссии Российской Федерации от 15 марта 2023 г. № 111/863-8 «О методических рекомендациях о порядке формирования территориальных, окружных и участковых избирательных комиссий». Образцы необходимых документов размещены на официальном сайте Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

Үз илемдә – үз телем

И туган тел, и матур тел...

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстандагы төрле милләтләрнең яшәеше, гореф-гадәтләре белән таныштыра, «Бер гаилә мисалында туган телне ничек сакларга?» дигән сорауга җавап эзли.

ЯКУТ

Казан

СИХРИ ГАИЛӘ

Кышка кергәндә, якут авылларында халык эчәр өчен су запасы, ягъни боз әзерли. Бергәләшеп тонналап балык тотып, Муңха бәйрәмен үткәрәләр. Ат ялыннан ясалган пумала белән явыз көчләрне куалар, коймак пешереп, рухларны сыйлыйлар. Башкалада яшәүче якут гаиләсе Алена һәм Матвей Семеновлар безне үзенчәлекле йола, гореф-гадәтләре белән таныштырды. Шулай ук якутларның тормыш шартлары, суыкны ничек җиңүләре һәм туган тел кадере турында да сөйләделәр.

Эшкә – Казанга!

Алена һәм Матвей Семеновлар гаиләсе өч ел элек Саха (Якутиядән) Казанга күченеп килгән. Дөресрәге, гаилә башлыгы галим Матвейга КФУда килешү буенча эш тәкъдим иткәннәр. Аңа – 41 яшь. Моңа кадәр 15 ел Якутиядә нефть һәм газ проблемалары институтында фән белән шөгыльләнгән. Хәзерге вакытта КФУда гидратлы газларга бәйле лабораторияне җитәкли. Тикшеренү нәтиҗәләрен скважиналарда кулланып караячаклар. Студентлары арасында фән белән кызыксынучылар да бар.

– Якутия – нефть төбәге. Бездә нефтьне табалар, әмма бик аз өлеше генә эшкәртелә. Бик салкын бит. Нефтьне читкә чыгару, логистика юк. Шуңа күрә бу өлкәдә белгечләр кирәк. Татарстан исә бу яктан алга киткән. Безнең максат – кырыс шартларда нефть табу проблемаларын өйрәнү. Өч еллык килешү төгәлләнде инде, тик аны дәвам иттерәчәкләр, – ди химик Матвей Семенов, әле туган ягына кире кайтып китәргә ашыкмавын белдереп.

Алена да фән өлкәсендә хезмәт куйган. Тик Казанда үзен башка өлкәдә сынап карарга булган. 37 яшьлек хуҗабикә үзмәшгуль булып теркәлгән. Семеновлар инде 13 ел бергә. Ике бала тәрбиялиләр. Миага – 12, Федорга – 9 яшь. Аларны татар мәктәбенә биргәннәр. Миа татар теленнән олимпиадаларда катнаша икән.

Суык куркытмый

Якутия дигәч, иң элек болан асрап көн күрүчеләр, юртада яшәүчеләр күз алдына килә. Шуңа күрә кызыксынуыбыз нәкъ шуннан башланды да инде.

– Әнием – Мирнинский районының Таас-Урэх («Ташлы елга» дип тәрҗемә ителә. – **Авт.**) авылыннан. Авылда сыер, мөгезле эре терлек, дуңгыз, кош-корт тоталар. Боланны бары төньяк районнарда гына асрыйлар. Төп кәсеп – терлекчелек һәм балыкчылык. Шулай ук бакчачылык белән дә шөгыльләнәләр. Якутларда элек ипи булмаган, көлчә генә пешергәннәр. Онны безгә руслар китергән, – ди Алена. – Татарстанга килгәч, киң кырларга карап шаккаттык. Шундый иркен алар. Бездә урман һәм кырлар янәшә диярлек.

Якутиядә йортларны агачтан салалар. Агачның үз төсен саклыйлар. Шуңа күрә аны төрле төсләргә әллә ни буямыйлар. Кайбер йортларның түбәсенең алгы ягы, чормасы юк. Җәйге йортлар, ягъни балаганнар да бар. Элек һәр ишегалдында ритуал символ – «сэргэ» урнашкан булган, хәзер барысында да түгел. Анда ат башы сурәтләнгән. Монысы инде – якут халкын ашаткан һәм техника чарасы буларак йөрткән бахбайларга мөнәсәбәт.

Мәктәп, кибет, клуб – авылларда барлык социаль объектлар да бар. Кибетләренә «махтал» дип язылган. Бу рәхмәт дигәнне аңлата. Димәк, кергәнче үк рәхмәт әйтәләр. Барлык дәүләт оешмаларында элмә такталар якут һәм рус телләрендә язылган. Мәктәпләрендә балалар якутча да белем ала. Температура 60 градуска кадәр җитү сәбәпле, укучыларның март уртасына кадәр ял иткән чаклары да булгалый.

– Салкынга ияләшәсең, әмма һәрвакыт калын киенергә кирәк. Кыш алты айга сузыла. Туңмас өчен күп итеп ит ашыйбыз. Тамакны җиңелчә ризык белән генә алдап булмый. Әмма шуңа карамастан, якутлар таза түгел. Казанда сөтле ризыклар, тавык, күркә ите ашыйбыз, – ди Семеновлар.

Суыкта яшәүнең кыенлыклары шактый булса да, аның каравы яшь күренәсең. Казанга килгәч, Семеновлар үз яшен әйткәч, күпләр моңа ышанмаган.

Боз – зур бүләк

Якутия авылларында чишмәләр юк. Монда – мәңгелек туң. Шуңа күрә Саха халкы ноябрь аенда кышка җитәрлек итеп су запасы туплый. Моның өчен күлдәге бозның калынлыгы 15–20 сантиметрга җиткәнне көтәләр. Кисеп, өйгә ташу өчен шулай уңайлы икән. Шул боз кисәкләрен ишегалдына бер кучкә өяләр. Кирәк саен, кисмәккә салып, эретеп эчәләр, юыну өчен кулланалар.

– Һәр өйдә башкарыла бу эш. Балалар өлкәннәргә боз әзерләргә булыша. Өйгә китереп бирелгән боз – зур бүләк. Бер кечкенәрәк кисәктән 3 литр су чыга. Тәме аерылып тора. Кайберәүләр бозлы суны җәйгә дә калдыра. Ә инде иренсәң, кышкы суыкта бәкедән ташырга туры киләчәк, – дип аңлата Алена.

Иң газиз туган тел!

Семеновлар якшәмбе мәктәбе укытучысы Айылана Новгородованы да кунакка чакырганнар иде. Әлеге мәктәпкә дүрт бала йөри икән.

23 яшьлек Айылана фотограф, видеога төшерүче булып эшли. Шул ук вакытта атнага бер мәртәбә якшәмбе мәктәбендә балалар белән шөгыльләнергә дә вакыт таба. Аларны укырга, язарга өйрәтә, якут халкының гореф-гадәтләре, мәдәнияте белән таныштыра. Һөнәре буенча – башлангыч сыйныф укытучысы. Өч ел мәктәптә укытып караган, хәзерге вакытта университетта читтән торып белем ала. Үзе – Якутиянең Таттинский районыннан. Казанны ул яшьләргә үсү өчен мөмкинлекләр күп булганга сайлаган. Шулай ук төрки тамырлар да тарткан күрәсең, ди.

– Чит җирдә телне саклау җиңел түгел. Шуңа күрә балаларны якшәмбе мәктәбенә йөртәбез. Укытучыны да өйгә чакыргалыйбыз. Иртән торуга Якутия хәбәрләрен кабызып куябыз. Колакларына керсен, дибез. Өйдә үзара якутча сөйләшәбез. Телне өйрәтү – безнең өчен зур бурыч, – ди Матвей.

Сүзгә Алена да кушылып, үз фикерен җиткерде:

– Якут телен гади мәктәптә өйрәнү мөмкинлеге юк. Шуңа күрә ул-кызларыбызга ике ел авыррак булды. Хәзер милләттәшләребезнең балалары белән аралашалар. Казанда 15ләп якут гаиләсен беләм. Балалар якутча аңлый, тик кайвакыт сорауларга җавап биргәндә төртелеп калалар. Ирем якутча китаплар укый, балалар тыңлый. Бездә шундый гадәт бар. Кичен өйне җилләтәбез дә һәркем берәр сәгать үзе теләгән китапны укый. Җәй көне каникулга әби-бабайларына кунакка кайтарабыз.

Башкалада үзләрен бик рәхәт хис итә алар. Халыкның мөнәсәбәте: аралашучан, ачык йөзле булуы ошый икән. Эш булганда, Казанда яшәргә ниятләсәләр дә, киләчәктә исәпләре Якутиягә кире кайту. Анда үз йортлары, машиналары бар. «Татарстан бик ошаса да, туган як, әти-әниләр барыбер сагындыра», – ди Семеновлар.

Шаманлык һәм ышанулар

Һәр икенче якутның нәселендә шаманнар бар. Бу юлны үтәр алдыннан алар бик нык авырый. Табиблар да ярдәм итә алмый. Моңа кадәр яшәгән шаманнар аларны төштә дәваларга өйрәтә. Әйтик, балык тоту уңышлы булсын өчен, коймак пешереп, рухларны ашаталар. Якутлар һәр ял көнендә пешерергә тырыша аны. Йортны начар затлардан арындыру өчен кирәк бу. Яңа урынга ял итәргә барганда да, коймак пешереп, шуны җирдә калдыралар. Үзләренчә рухларны шулай сыйлыйлар.

12–13 июль – рухлар көне. Бу көнне алар урамга чыкмыйча, өйдә тыныч кына утыра. Эшләмиләр, көләргә һәм кычкырырга ярамый. Янәсе, рухларның теге дөньяга алып китүе бар. Икенче көнне печән өсте башлана.

– Сабыйлар еш үлә башлагач, борынгы якутлар моны бары начар рухлар галәмәте дип уйлаган. Бу күренешкә каршы көрәшү өчен ирләр озын чәч үстергән. Имеш, шулай куркытканнар, – ди укытучы Айылана.

Ат ялыннан саклагыч бөтиләр, шулай ук дэйбиир дигән аксессуар ясыйлар. Аның белән элек бөҗәкләрне кусалар, хәзер матурлык өчен тоталар. Шулай ук дэйбиир начар затларны үзенә якын китерми. Аны селкетеп, яшәгән фатирларын тискәре энергиядән чистарталар. Янәсе, алар шул пумаладан курка.

Гореф-гадәтләр

Милли бәйрәмнәр

Муңха – Якутиядә боз астыннан кәрәкә балыгы тоту бәйрәме. Ноябрь аенда саха халкы елга буена җыела. Учак ягып, шуны өч тапкыр әйләнеп чыгалар. Тонналап балык тотып, килә алмаучыга да өлеш чыгаралар. Мәет җирләүдә катнашучылар 40 көнгә кадәр бу чарада катнаша алмый. Шулай ук көмәнле хатыннарга да килергә кушмыйлар.

Куйуур – февраль ахырында уза торган балык тоту йоласы. Бозны тишеп, ятьмә салып, аны сәгать теле уңаена әйләндерәләр. Бәкедә башта бер генә балыкчы тора, соңыннан табышны бергәләп тартып чыгаралар.

Ысыах – Якутиядә табигатьнең уянуына бәйле рәвештә уздырыла торган бәйрәм. Гадәттә иң озын көндә – 21 июньдә үтә.

Ысыах бәйрәме вакытында гыйбадәт кылу йолалары үтәлә, милли уеннар уйныйлар, милли ризыклар белән сыйланалар, ат чабышлары оештырыла. Якутлар милли киемнәрдән киләләр. Казанда яшәүчеләр аны Мирный бистәсендәге мәйданчыкта билгеләп үтә. Иректе көрәштә көч сынашалар. Бөтенесе бергә кояшка таба әйләнәләр.

Йола

Элек балага 40 көннән соң гына исем кушканнар. Бер айдан соң гына кунакка чакырганнар. Күз тимәсен өчен көмеш бөти элеп куялар.

Киемнәр

Милли киемнәрендә һәр бизәк, тамга нәрсәнедер аңлата. Арада сәламәтлек, байлык, муллыкка кагылышлылары да бар. Күбрәк кояш рәсеме сурәтләнгән. Алар аны барлык бәла-каза, начар гамәлләрдән саклый дип ышана. Шулай ук көмештән ясалган бизәнгечләр тагалар. Ирләр, хатын-кыз, балалар костюмнары бер-берсеннән аерыла. Якут ирләре билләренә пычак (быһах) тага. Милли бәйрәмнәргә шулай йөриләр.

ВИДЕО

Сәхифәне Сәрия МИФТАХОВА әзерләде
Фото – Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 4668 данә
Гомуми тираж – 13856 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 204

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+